**Айдар Хәлим**

**Колмак җыя кызлар**

**Шигырьләр, балладалар**

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 821.512.145-1

ББК 84 (2 Рос=Тат)-5

Х87

**Хәлим А.Н.**

Колмак җыя кызлар: шигырьләр, балладалар / Айдар Хәлим.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.— 208 б.— 2000 д. — ISBN 978-5-298-01693-3

Шагыйрьнең әлеге китабына төрле елларда иҗат иткән лирик-фәлсәфи шигырьләре һәм балладалары туплап бирелде.

УДК 821.512.145-1

ББК 84 (2 Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01693-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Хәлим А.Н., 2008

# Яна-яна иҗат итә

Айдар Хәлим — үзенең яшәү рәвеше, иҗтимагый гамәле, иҗади эшчәнлеге белән безнең хәят-яшәвебездә феномен күренеш. Моны бүген кемнәрдер таныймы, инкяр итәме яки махсус күрмәмеш-белмәмешкә салынамы — анысы мөһим дә түгел, әмма Вакыт галиҗәнаплары бу шәхеснең кабатланмас зурлыгын әкренләп раслап килә инде.

Әдәби даирәдә Айдар Хәлим (баштарак ул паспортындагыча Борис Хәлимов булып таныла башлады) исеме инде кырык еллап даими ишетелеп, аңга сеңеп килә. Элегрәк, 60 нчы елларда, ул, башкалардан әллә ни аерылып тормыйча, дистәләгән яшь һәм башлап язучылар исемлегендә йөрде. Җәмәгатьчелекнең күз уңыннан югалгалап торган чаклары да булды. Әле Башкортстанда, әле Татарстанда, тагын әллә кайларда яшәп-яшәп алулары да, күрәсең, моңа сәбәп булгандыр. Ул шулай ук әдәбиятта «Фәйзуллиннар буыны» (мин чыгарган термин түгел!) дигән обойма-исемлектә дә саналып йөртелмәде. Гәрчә ул яшь һәм иҗат башлангычы потенциясе белән нәкъ шушы буынның табигый талантлы бер вәкиле булса да. Хәер, мондый шартлы дифференциянең хаҗәте дә шуның кадәр генә. Ахыр чиктә һәр иҗатчы үзенең намусы, вакыт һәм халык алдында япа-ялгыз, бергә-бер бит! Әнә тәнкыйтьчеләргә барлар өчен җайлы булган буын-төркемнәргә кермәгән Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар, прозада — Миргазиян Юныс һәм Адлер Тимергалиннар, драматургиядә Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллиннар үзләре бер тылсымлы иҗат дөньясы тудырмадылармыни?

Айдар Хәлим — бу дөньялыкта Яшәү казыгын нык каккан әдип. Таныйк: соңгы 10–15 ел эчендә ул халыкара масштабтагы фигурага әйләнде. Аны һәр даирәдә шактый ук яхшы беләләр: гади укучылар да, сәясәттәге эшмәкәрләр дә, хакимият-күзәтү вәкилләре дә, чит ил даирәләре дә... Хикмәт нидә? Шагыйрьлеген, язучылыгын таныган хәлдә, миңа калса, ул иң әүвәл бүгенге көннең иң актив милләтпәрвәр публицисты. Ул ике башына да ут капкан шәм шикелле. Өстәвенә уртасын үзе үк бик теләп яндыра шикелле. Күрәсең, генетик коды шундый. Ул гүя МЧСның бер җаваплы идарә пультында. Кайда хәвеф, кайда бәрелеш, кайда яра — Айдарның каләме шунда. Соңгы ун елда чыккан китапларын искә төшерик: «Книга печали, или Записки аборигена», «Гомеремнең ун көне», «Этот непобедимый чеченец», «Минем Түгәрәк Имәнем»... Кайберләре, үзебездә мөмкинлек табылмагач, чит илләрдә басылган, суд-мәхкәмә чикләрен үткән... Аннан да кыюрак, зирәгрәк, гайрәтлерәкләр бар икән — әйдә, андый әсәрләрне үзләре язып күрсәтсеннәр! Бу китапларның берсе генә дөнья күргән очракта да, тарихта урын дәгъва итәргә мөмкиндер ул.

Кайчак уйлап куясың: ничек шулай төрле яклап универсаль югары кимәлдәге профессиональ иҗат итеп була икән?

Көндәлегемә беркөн болай дип язып куйганмын:

Үзең генә язмыйсыңдыр! —
җеннәрең булышадыр.
Публицист, прозаик,
драматург,
шуңа өстәп шәп шагыйрь!

Айдар Хәлим ике телдә — рус һәм татар телләрендә (теләгәндә, саф башкортча да!) иркенләп иҗат итә ала. Сирәк хәл. Аңлаганнар өчен ул зур шагыйрь («Милли шигырьләр» китабын гына укып карагыз!). Шагыйрь булам дип башлаган иде иҗатын — максатына иреште. Өстәвенә балалар өчен дә менә дигән шигырьләр яза. Бусы — талантның зурлыгын белдерүче бер сыйфат. Театр дөньясы өчен пьесалары да яхшы мәгълүм... Әмма, минемчә, соңгы еллардагы төп иҗади хезмәте ул — проза әсәрләре. Кайберләре аерым китап булып чыкты, кайберләре әле әзерләнә генә дип беләм. Шулай да төп проза әсәрләре — «Өч аяклы ат», «Татар вакыты», «Казыктагы итальян» — «Казан утлары»нда үз вакытында

басылып чыктылар. Кемгә ничектер, бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге дип бәялим мин бу әсәрләрне. Теләгәндә, теләсә нинди дәрәҗәдәге премия, бүләкләргә лаеклы әсәрләр.

Айдар Хәлим — һәр зур талантка хас булганча, гаять катлаулы һәм каршылыклы шәхес. Дөрес, аны тирән беләм дип әйтә алмыйм, нык аралашып бер мохиттә яшәлмәде, холкын һәм гамәлен күзәтүләрем буенча шулай дип уйлыйм. Ярсулы, ашкынулы, кайнар әдип. Җанындагын, күңелендәгеп әйтеп калырга өлгерә алмамдыр дип бәргәләнә-кабалана да бугай ул. Кайчак уй-фикерләре, хис-тойгылары кирәк дәрәҗәдә «утырып» та өлгерми, алар инде ялкын йә хәнҗәр булып кемнәрнедер яндырып, яралап та өлгерә. Кайчак берәр затны өскә чөйгәндә, бүтән берничәне билгә кадәр батырып та куйгалый... Нишлисең, талант табигате хәлләре... Иман һәм талант хакына кайбер чиктән чиккә ташлануларны кичерергә дә туры килә. Әйе, ашыга Айдар. Ашыгырсың да шул: төрле төбәк-кыйтгаларда сүнеп бара торган татар учакларына тын-сулыш өрергә өлгерергә кирәк! Бүген үк, хәзер үк! Иртәгә инде соң булуы бар... Ул гел юлда кебек миңа. Әле Урта Азиядә, әле Кавказда, әле Урал якларында, Оренбург далаларында... Сүз уңаеннан Айдар Хәлимнең биш ел буе татар халкының Милли Мәҗлес рәисе булуын да искә алып үтик. Дөресен әйтим, аның бу хезмәтенә, эшнең асылын һәм нәтиҗәлелеген тиешенчә белмәү сәбәпле, бәя бирә алмыйм. Милләт мәнфәгате өчен саулыгын, рух җегәрен кызганмый янып йөрүен генә беләм. Күрәсең, дөньялыкта һәммәсен дә колачлап бетереп булмый торгандыр. Бәлки, Милли Мәҗлес башлыгы өчен Садри Максудига хас сыйфатларга ия булырга кирәктер, халкыңның да XX гасыр башындагы кебек ишле һәм бердәм булуы шарттыр...

Соңгы елларда Айдар Хәлим үз иҗатында тагын да ныграк үҗәтлек (сокланып әйтүем!) күрсәтеп, яңа үрләр яулады. Җәмәгатьчелек тә моны таныды, бәяләде. Алга таба бәяләү векторы тагын да югарырак күтәреләсенә шигем юк. Бу очракта мин аның «Казан утлары»нда чыккан «Сез беләмсез кая барганны?» исемле күләмле, ярсулы тәнкыйди-публицистик мәкаләсен һәм күппланлы «Хунвейбин» дигән романын һ.б. шундый әсәрләрен күздә тотып әйтәм.

Айдар Хәлим — үз дәрәҗәсен бик яхшы белеп иҗат итә торган әдип. «Үзем турында үзем» дигән язмасында мондый юллар бар: «Мин үзем турында татарның киләчәге булган һәм, һичшиксез, Тукай йолдызлыгыннан булган зур шагыйрьмен дип уйлыйм... Мин исән чагында «тарихта үземне булдыру» түгел, анда милләтне булдыру өчен көрәштем һәм чамасыз кан һәм көч түктем. Милләт булсын! Бу — иң мөһиме. Милләт булса, без дә булырбыз, Аллаһы боерса. Милләт булмый икән, без була алмыйбыз. Без ул чакта беркемгә кирәкмибез». Килешәм, каләмдәш дустым. Тик шунысын да өстәп әйтим: без бик кирәк әле бу дөньяда! Синең олуг иҗатың кирәк! Исән-сау гына бул!

*Равил Фәйзуллин*

## Кереш сүз

Сүзләрем минем
Челтер-челтер аккан
Шарлама чуерташлары булып
Ялтырасын иде.
Сүзләрем минем
Корычларда чыңлап
Яңгырасын иде.
Сүзләрем минем
Илем ындырларындагы
Көшелләргә аккан бодай булып
Шылтырасын иде.
Сүзләрем минем,
Курай моңы булып,
Халкым күңелен мәңге
Иркәләсен иде.
Сүзләрем минем,
Өязе-елга камышлары кебек,
Җилләр кочагында
Дулкынлансын иде.
Шигырьләрем минем —
Йөрәк тамырларыннан сызылып чыккан
Сабыйларым минем —
Комлыкларга очыгыз,
Иреннәрен чылатырга су тапмаган юлчы
Җырларымның зәңгәр чыгын эчсен.
Баррикадаларга очыгыз.
Азатлык көрәшчеләренә ак яулык болгап
Диңгезләр кичегез.
Алга, яктылыкка!
Сүзләрем минем,
Курыкмагыз!
Әгәр мин көрәшче икән,

Сез — минем коралым.

*1965*

## Туган җиремә

Тальян моңына төренеп йоклаган алка таулар,
Болыннарда аҗагандай уйнаклап йөргән тайлар,
Кызлар яшедәй саф чишмә, баланлык-әрәмәләр,
Кәүсәсенә, умарта күк, бал җыйган карамалар,
Туклыкка ниятләп пешкән балавыз арышларым,
Шатлыкларым орлыгыннан гөл ярган сагышларым!
Әй, изге йолдызлар иле! Син минем туган ягым,
Хуш исле юкә бишектә тибрәнеп үскән чагым...
Һәр ташың, җирем, тарихтан җиткерә сихри аваз,
Тыңла да ятып шул ташны, либретто, опера яз!
Һәр тарафың — чәчкәлек, һәр төшең бөтен, камил;
Һәр кешең миңа туган: булсын Камил, булсын Шамил.
Утларын-суларын кичеп яшәсәң халкың белән,
Ул исем баета хисне сүрелмәс ялкын белән.
Җил какса да, моңын түгә челләдә көйгән курай,
Яшьтән кайгылар күп күргән кеше дә шулай бугай.
Тальян тавышыннан уянып, бишектән төштем дә мин,
Төймә кадәр зиһенемә сыйдырып җирнең ямен,
Өметен көлгә яшереп, тын алган далаларга,
Итәк тулы бала белән тол калган аналарга,
Ирләр тавышын юксынып җәйрәгән басуларга,
Ятим яшьлекне ләгънәтләп кайнаган ярсуларга,
Их, җырладым «Таштугай»ны, тургайлар куансын дип,
Җырладым тауларга басып, үзәннәр юансын дип...
Яшәвемнең кыйбласыннан кан табын юдың, дөнья!
Мең тапкыр «үлдем» дигәндә, илһамың бирдең, дөнья!
Җир миңа — хезмәт һәм хөрмәт, җир миңа — рухи азык!
Ил шунда — кайда бабайлар йөрәксеп каккан казык!

*1967*

## Туганнар каберлегендә

Май кояшы җитен көлтә булып
Тишеп керде яфрак түшәмен —
Туганнарым яткан каберлеккә
Пилоткамны салып үтәмен.

Карт парк бу.
Салкынлыгын таңның
Куенында саклый имәннәр.
Нурдан уяна да
Күбәләкләр
Очып чыга юеш үләннән...

Тыныч йокы сезгә, көрәшчеләр!
Кояш нурын сезгә мул сибә.
Күккә баккан гөлләр керфегендә
Акрын гына зәңгәр чык кибә...

Гүя гаскәр монда туктап калган...
Кояш тәгәри рәтләр алдыннан.
Җир кара да,
Ник соң гөлләр алсу —
Шытканнармы солдат канынннан?!

Татра тавы итәгендә дә бит
Бер кабер бар — атам күмелгән.

Шунда солдат — минем чех туганым
Сакта тора сыман күңелдә...

...Мин өч көнлек.
Ә аңа — фронтка.
Январь карын ярган чаналар...
Елаганмын,
Әйтерсең шунда ук
Югалтуга барган чамалар...
Ә давылга нәрсә, тилергән дә
Җил капканы безнең җимергән,
Әмма ил капкасын саклаганда,
Атам түгел, дошман җиңелгән!

Солдат йоклый...
Күзне кургаш сыман яшь йота.
Юк, яшь түгел!
Бу — өченче буын
Кабрегездә сезнең ант итә.

...Йокыгыз тыныч булыр, көрәшчеләр! —
Быргы чакыра. Ары китәбез.
Еламыйбыз.
Сезнең гомер — бездә,
Еламыйча антлар итәбез.

*1962*
*Литва, Кибартай*

## Җылы икмәк-җирем

**1**

Солдат итегендә таптап киләм
Балавыздай арыш камылын.
Менә хәзер
Таулар шәлен ташлап,
Йөгереп чыгар авылым...

**2**

Бездә таулар кичен,
Кызлар кебек,
Түгәрәккә бага җырларын.
Бездә таңнар,
Кызыл быргы уйнап,
Чәчкәләргә урый Дим ярын...

**3**

Үскән бишек... Ачып чыккан ишек...
Алка таулар... Монда халкым бар!
Җылы икмәк-җирем күкрәгенә
Кайтып капланырлык бәхетем бар!

**4**

...Солдат итегендә таптап киләм
Балавыздай арыш камылын...
Менә-менә
Таулар шәлен ташлап,
Йөгереп каршы чыгар авылым...

*1962*

## Кояш көнчыгыштан китек чыкмас...

Сыек томан, зәңгәр ситсы булып,
Иңен салган инеш үренә.
Чәчәк аткан шомырт ак халатлы
Савымчы кыз кебек күренә...

Чәчәк керфегендә — салкын чыклар.
Таңда изрәп йоклый табигать.
Хәерле көн, дуслар!
Алдыгызда —
Сезне сагынып килгән бер солдат!

Сихри тынлык.
Без яраткан тынлык.
Әй бай да бит нурга бу һава!
Иркә тынлык.
Нинди гүзәл тынлык!
Сары томан булып бал ява!..

Күпме язлар,
Кояш нурын сагынып,
Таңда күзләрегез ачканда,
Аһ, юк, болыннарда
Шартлау ташкын булып ташканда,
Еллар сезне кырыс хөкем итте...

Яз чәчәксез икән — җир елый!
Дары исе дөнья агулый.
Чәчәкләргә иртән бал ява.
Кайда дары — шунда кан ага.
Гөрлә, инеш, гөрлә!
Җырлап яшә!
Нинди зур булмасын бомбалар —
Көнчыгыштан кояш китек чыкмас,
Кайта-китә торыр торналар...

...Тау артыннан кояш күзен кыса.
Хуш ис аңкып торган букетны
Походларда
Кырык михнәт күргән
Котелокка кертеп утырттым...

*1962*

## Тальян моңы

Бусагамнан бөтен нәсел-ыруым
Озатканда мине солдатка,
Әйтте анам:
— Җырыңны югалтсаң,
Кайтасың юк, балам, бу якка!
Яшьнәде кодрәтле яшен,
    айкап күз алмасын.
— Тальяным бир, бир тальяным, анам,
Ялгызы калмасын!

Яулык чите белән яшең сөртеп,
Сүзсез калдың басып ак ташка.
Мин утыргач, ярсып кешнәде дә

Киң юлларга чыкты ак кашка.
Тальяным моңыннан
сискәнде кыялар!
Бала чактан мине
аңлый алар!..

Яшәп килгән гади хакыйкать бар:
Күкрәп җиргә килгән ир бала
Тугрылыгы яуда гына түгел,
Тып-тын тауларда да сынала.
Уйнады ла, ай, өзелде тальяным,
Артта калды анам, илем, ярым...

Солдат юлы йөгерек сукмак түгел.
Хисләр анда түгәрәк төс ала.
Хезмәт бөек:
Ул таш йөрәккә дә
Җир тойгысы дигән җим сала.
Сизенә тальяным —
    нәрсәдер бар!
Зәңгәр җил, анама
    җыр алып бар!
...Кайгы мине танкодромда тапты.
Кара болыт килеп люкны япты:
— Үл-де... үл-де-еү...
Синең анаң үл-де-еү...
Белмим, шуннан әллә нәрсә булды...

Эскарплар*, таулар, полигоннар,
Блиндажлар, буш гильзалар һәм чишмәләр
Күзләремдә куышып әйләнделәр...
—Ялган, һич ышанма, — диде дуслар.
—Ышан, — диеп пышылдады таулар...

Соң инде, соң, бәгърем, ялың чайкап,
Тоякларың бәрмә как ташка.
Тулпарымның тавышларын ишетәм:
Туган якта үкси ак кашка!..
Ана үлсә, илгә кайгы ята,
Бер кайгыга мең шатлыгың бата.

Хәсрәтләрдән ут кабызды җырым.
Ярлар үлми, чишмә туңмаса.
Тик шулай да, дуслар, кайчак мине
Тальян күтәрә алмас моң баса...
Җыр югалтсам, җирдә ни кала?
Син йөрәгем төере, Ил-Ана...

*1966*

## Кил бире, күз алмам!

Тауларда таң туса,
Тауларга ашкынам.
Тауларым — атлы яуларым,
Күбекле ташкыннар...

Тауларда бер кыз бар.
Кил бире, күз алмам!
Кайгыга түзсәм дә,
Сагынуга түзалмам...

Күрәсең, онытты,
Сәлам юк — хат язмый.
Тауларда — болытлар,

Күк һаман аязмый...

*1965*

## Язгы яңгыр

Кешнәде, ләйсәнне чакырып,
Җәйләүдә айгыр.
Тирәк очларыннан шаулап
Узды язгы яңгыр...

Саумы,
Илнең аяз язы!
Уйланыр көннәр...
Гөрелдәп килгән бу язда
Яңа җилкәннәр...

Кояш гашыйк тирәгенә
Алкалар тага.
Ә тирәк, йөгерә-йөгерә,
Кыңгырау кага!

Чың-чың иткән чыңтавышка,
Килче, күр әле! —
Күбекләнеп күтәрелә
Бәбкә үләне...

Карагыз, сибәм, әй сибәм
Алтын тәңкәләр.
Тәңкәләр түгел, хәтфәдә
Сары бәбкәләр...

Тирәк очларыннан шаулап
Узды язгы яңгыр.
Җир бөек туйга ашкынган
Ир-егет хәзер...

*1966*

## Иркәлә, бәгърем...

Ай сусап елгага төшкән,
Нурлар кайтара...
Алтын буразна су өстен
Урталай яра.
Яр буенда — егет һәм кыз.
Шомырт исләре...
Шигырь итеп укый егет
Сөю хисләрен.
Кызның дымлы керфеккәе
Керфеккә тиде.
Гүя ул серле талпынып
Ялвара иде:
«Сөенеп сөеләсе вакытым —
Иркәлә, бәгърем...
Сирәкләп кенә булса да
Үпсәнә, бәгърем...»

*1964*

## Әманәт

Акчарлаклар, тере дулкыннарга
Тавышларын сибеп, каядыр
Югалганнар;
Кабилә-кабилә дулкын
Күкрәгемне юа шаярып,
Миннән кире китә яшәреп:
Тыңла, егет,
Тыңла,
Акчарлаклар
Тапшырырга кушты
Әманәт.
Гөлең корыр,
Әгәр яшьлегеңнең
Хыялына итсәң хыянәт.

Бар дулкыннар китте, берсе калды,
Сабый кебек керсез рәвештә
Ашыгып сөйли нидер колагыма,
Дөнья дигән авыр ярышта
Көрәшергә куша һәр эштә:
Күңелсезгә күлмәк
Кидермиләр,
Кидермиләр,
Өстеңдәге агын
Уңдырма,
Уңдырма.
Күзләреңдә халкың иҗат иткән
Утларыңны сакла,
Сүндермә,
Сүндермә,
Сүндермә!

*1968*

## Колмак җыя кызлар

Өязекәй буйларында туган як гүзәлләре
Бергәләп колмак җыялар, гөр килә үзәннәре.

Кызларымның буй-сыныннан көнләшә тал — нечкә бил.
Нечкә бил талларга кунып, хискә баткан йомшак җил.

Күзләреңдә мәхәббәтнең чакма ташы чаткысы.
Кемнәргә бәхет китерер бу күзләрнең яктысы?

Ургылып аккан толымнар, сез таулар чишмәсеме?
Мин таулар сафлыгын мактыйм, кызларым, ишетәсезме?

Аяк асты абага, абага чыгын кага.
Абагаларга сарылып, талгын гына җыр ага.
Өязекәй — омтылып ла аккан су,
Вай-вай-вай,
Синнән башка күңелем ямансу...

Туктамый җыегыз колмак, туктама, җыр, туктама!
Колмак булып итәкләргә алкалы бәхет тама...
Өязекәй буе тал-тирәк, шул,
Күңе-е-лең якын иткә-ә-ән яр кирә-әк...

Кызлар күңеле — кыңгырау, җәелә кыңгырау чыңы.
Әй чыңлый,чыңлый кыңгырау, чөнки нәкъ чыңлар чагы.

Туйлар белән гөрләп тора кышларын туган ягым.
Авылдаш куя табынга бавырсак, ачы балын.

Мин кайтырмын, гүзәлләрем, тауларда күлләр тонгач,
Чут-чут итеп сайрар шулчак йөрәгемдә сандугач.

И җирем, түгәрәк табын, ап-ак шәлеңне ябын,
Ябын да ап-ак шәлеңне шәмдәлләр булып кабын!
Кабынсын шәмдәлләр булып Өязе үзәннәре,
Яшәсен тауларда үскән авылым гүзәлләре!

...Өязе-елга буенда кыз-кыркын колмак җыя.
Бу гүзәл эштән кызларны, әйтегезче, кем тыя?

*1966*

*** * ***

Тарих кирәк кешесен һәрчак таба.
Бастилияләрнең гыйсъянын
Айлы күңелләрдә чайкар өчен,
Җиргә пәйда булган Бетховен.

Саф аһәңне ишетеп аһәң тынган;
Ә төн якты — китап укырлык!
Аваз салгач кылга бөек Чукрак,
Кылда үлгән тома сукырлык.

Кулын сөртеп, шагыйрь каурый алды,
Аккош хоры каурый эчендә.
Яңа Бастилияләрне җимерәчәк
Дәрман көйри үткен очында.

*1967*

## Гади күренеш

**1**

Купты дөнья, купты галәм,
Гарасатка килгәч илһам.
Йолдызларны җиргә орып,
Давылларга чумды җиһан.

Ыңгырашып һәм сулкылдап,
Ут йота җир гөр-рес-гөр-рес,
Кемнең монда хисе камил,
Кемнең монда акылы дөрес?

Чатырдап китә дә яшен,
Төшеп тауларга сылана.
Кешеләр күк, разбой салып,
Таулар яна, таулар яна...

Яшеллекне көпә-көндез
Каплады төн — кара сагыз.
Нишлим, күктә сүнә йолдыз,
Суларда үлә бит кондыз?

Әрнесәм дә, туктатырга
Дәртем зур, тик җитми дәрман,
Яшәү белән үлем шулай
Тоташкач бер җепкә тәмам...

**2**

Аһ!
Капылт бушанды киңлек,
Китте яңгыр, койма яңгыр,
Койды яңгыр, инде койды.
Имеп туйган сабый сыман,
Күкрәк тутырып тын алды җир...
Көлде кояш, качты газап,
Дөнья гаҗәп, дөнья гаҗәп!

Тәнгә — сихәт, тәнгә — рәхәт,
Инде җирдә үтә тыныч.
Хәрәкәттә — бәрәкәт, дип
Ага тормыш, ага тормыш...

Давылның һәр мизгелендә
Ышанып яңару барга,
Елгалар да кайтты ярга,
Һич зарланмый ярлар тарга.

Өер-өер елкылардай,
Суга төшкән тауларымның
(Күмерләнгән ялларыннан
Кучкылланып сулар ага!)
Тезмәләре, гаҗәпләнеп,
Кинәт тынган, әйтерсең лә
Комда күреп алтын дага...

Актарылып тамыры белән
Ярда ята яшь бер тирәк —
Яфракларына төренеп,
Җан бирүдән баш тарткан да
Леп-леп тибә яшел йөрәк...

Җиргә мәгъшук, җырга мәгъшук,
Һәлак булган купшы зирәк —
Тамырлана башта уйлар,
Туктау өчен форсат эзләп...

Мин үзем дә давыл кебек,
Кайчак бик кискен алдырам.
Тауларыма ут төртәм дә
Үзәннәрне тол калдырам...
Ә соңыннан үксү катыш
Аһәң белән җырлап китәм.
Һәр сүземә, сандугачтай,
Гәүдәм белән сыеп бетәм...

**3**

Сау бул, тирәк, канлы йөрәк!
Сәлам биреп иминлеккә,
Гүзәл итеп яшәп калдың,
Гүзәл киттең чиксезлеккә!

Әйт син, Кеше, янып төшкән
Йолдызларга галәм тармы?
Бирче җавап, рух чишмәсе,
Кешегә хак үлем бармы?

Минем Гаклым һәр яфракта
Танып югалмас җирәбә,
Таш һәм космик гасырларның

Үлемсез берлеген таба...

Давыл булса, көчле булсын!
Давылдан соң калсын хис-ямь.
Нәрсә, яшәү булып килеп,
Үлем булып җирдән китсәм?

*1967*

## Бу күзләрне кайда күрдем соң мин?

Күзләреңдә — яшенле яңгырлар...
Яшеннәргә кагыла-кагыла,
Гомеркәең буе карашыңда
Бала тургай канат кагына...

Болыт баса,
Күкләр актарыла!
Тургай исән — керсез сафлык бар!
Шатлыгы да тулы булмас иде,
Яшәвендә олы хаклык бар!..

Әллә гасырларга җавап итеп
Тургай җанда күкрәү уята?
Каушар иде — юеш канатында
Мең шагыйрьгә җитәр моң ята...

*1966*

## Үзем турында

— Акыллы бул! — диләр миңа кайчак.
Оныталар —
Акыл шуңа кирәк, кемдә — юк;
Мин акыллы, диеп,
Милли хисләремнең
Гөлбакчасын таптар хакым юк.

Күпләр миңа, тыйнаграк бул, диләр;
Тыйнак эшлә, диләр, эшеңне.
Ә мин әйтәм:
Сезнең җебегәнлек беркайчан да
Күтәрә алмас минем исемне;

Яшермичә эшлим эшемне,
Куәтемне тоям, көчемне,
Кемгә бирим ташкан хисемне?

Минме әллә милләтләрне сөймим?
Минме әллә дуслык хәтәр, дим?!
Планетага яланаяк басып:
— Бар халыкны сөй син, татар! — дим.

Бар халыкны сөй син, татар, дим,
Дуслар белә — юкка вакланмыйм.
Чәчкә атсын бөтен дөнья, дим,
Чәчкә атсын гүзәл Ватан, дим.

Шовинистлар үтә нечкә хәзер.
Космополит, ай-яй, модада!
Халыкларны тар күпергә кертеп,
Кай халыкка карап «сюда» ди,

Кай халыкка карап «туда» ди.
«Кушыл тизрәк» диеп кодалый.

Тезелегез рәткә, сыбызгылар!
Мунча кертәм сезне ышыкта!
Үзегез күк сасык, бозлы суда,
Себеркесе яхшы шелектән*.

Мин булмышым белән республикан,
Бар атламым белән демократ.
Мин халкыма зур ышаныч йөртәм,
Ә сөюне сатмыйм тураклап.

*1966*

## Сезгә

Берегез утка салды, икенчегез
Йөрәгемә бозлы су сипте,
Өченчегез урман сукмагында
Чык кибүен көтте,
Кичекте...

Аһ, тәү тапкыр күрдем солыларда
Таң сарысы сыман бәсәрү!
Сагынсам да, елап саргайсам да,
Килмәс миңа кабат яшәрү!..

Сез күрәсез микән, сылуларым,
Солыларда көмеш бәс ята?
Шушы тамашаны әллә нишләп
Пар аккошлар бигрәк ярата...

Тынам, дуслар!..
Инде тальяныма
Таңның алсу нуры үрелми.
Мин — хәстәрле!
Ни дисәң дә — тормыш!
Менеп киләм текә үреңнән...

Җир вак җаннар белән тулы әле!
Ялгыз йөрәгеңне өч итеп
Яндыр син, кыз кеше!
Төн чигенсен,
Артка ятсын шәүлә, үч итеп...

Кызлар, кызлар,
Җанкайларым минем,
Телим сезгә бәхет-сәгадәт!
Сездән алда тупсагызга ятсын
Пар балдаклы тигез мәхәббәт.

*1967*

## Баймак

Үзем сайлап бу кыяга бастым.
Уңда — Баймак, сулда — Ирәндек*.
Нинди матур, нинди ихлас киңлек,
Нинди ярсу хисле тирәнлек!

Аһ, гали зат, Ирәндеккәй сылу,
Мин бит сиңа үги ул түгел.
Туганлыктай кайнар яше белән
Ташларыңда үкси саф күңел.

Мин бу якны үлеп үз күрәм шул!

Чын тауларны таныйм аръяктан.
Халкым мине таулар йөзегендә
Юмарт орлык итеп яраткан.

Иҗек чемчеп йөргән чиста шагыйрь
Түгелмен мин — мескен дәрвиш тә.
Тормышка мин атылып килеп кердем
Изүләрем чишкән рәвештә.

Үз оясын гына күрсә бөркет,
Туган төяк тавы ни әйтер?
Юлда үлсәм, илгә атым кайтыр,
Тоягында көмеш чың кайтыр...

Монда килгәч, моңлы зәңгәрлеген
Куелатты күзләр тагын да,
Үз халкымның таулар белән төргән
Йөрәген күрдем Баймак ягында.
Баймак, Баймак! Күңлең — айлы тугай!
Болытларга җиткән кыялар,
Әйтерсең лә, морадына җитеп,
Җиргә төшеп яткан хыяллар...

Баймак, Баймак... Җиләс күлләр иле!
Аең да бит алтын көймә күк.
Йолдызларың һәрбер изге хискә
Чишелергә торган төймә күк...

*1967*

## Тубин җыры*

*(Җыр)*

Ирәндеккәй-кыя, туган оя,
Оясында бөркет хәл җыя.
Уңга канат төртсә — Европа шул,
Сулга канат төртсә — Азия.
Тубин, Тубин,
Алтын каласы.
Моңланмачы, дала баласы.
Ирәндектән йөгереп суга төштем,
Сапсал-суны бүлә кирт-кирт яр.
Җырдан алып җырга салганда да,
Җырга туймас халык — башкорт бар.
Тубин, Тубин,
Алтын каласы,
Бу кадәр моң каян аласың?
Йөз ярып ла ята Ирәндек,
Ташта пешә курай кызарып.
Бәрәкәтле Түбә туфрагында
Кияү чыкмый калган кызлар юк.
Тауларда, һай, болан баласы,
Моннан мәллә кәләш аласы?

*1967*

## Курай

Нур тулган алтын камыш ул — син, курай!
Зиндан җимергән тавыш ул — син, курай!

Дөньямның күңел кылы ул — син, курай!
Беренче ләйсән яңгыры ул — син, курай!

Имгәнми юлдан киләмен, рәхмәт, курай!
Җырларга рөхсәт бирдең, рәхмәт, курай!

Туган якта беренче дус ул — син, курай!
Яшә, яшә, изге курай — язгы тургай!

*1967*

## Атлар көткәндә

Кабынып сүнде шәфәкъ, таралды атлар,
Коенды актан эңгер, уянгач ай-сеңел.
Туплап бар сафлыкны һәм пакьлекне хуплап
Тели кочарга җиһанны чын яраткан күңел.

Ләззәтледер бу мизгел, анда бар сихри көч,
Бар тапланмас горурлык, иркенлек, татлы тәм.
Инде онытылдым дигәндә...
Чү!
Тынлыкта йөзгән
Елкыларның керт-керт үлән өзгәнен ишетәм...

*1967*

## Иртән талга көмеш урала...

Уйнамачы курай, Ядкарь агай,
Таң җилләрен әрнеп уятма.
Яктылыкның тонык дымын җыйган
Керфегемне яшькә чылатма,
Куйчы, дала җилен елатма!
Авыр миңа, ай-һай моңсу миңа!
Җылы кулың теркәп йөрәккә,
Җавап бирә алсаң, әйтче, картлач,
Кайтмас микән Бабич бу якка?
Дөрес тибәр иде йөрәк тә...
Ядкарь агай, аңлат, ник иртәсен
Талга көмеш томан урала?
Ник соң яшьлек, сабан тургаедай,
Уйнап туймый, сүнә, югала?
Иртән талга көмеш урала.
Аңлат, нигә үлән өлгергәндә,
Ана күкрәгенә сөт төшә?
Ник кавын күк ай пешкәндә, күктә
Ир башына җитди уй төшә?
Кавын кебек күктә ай пешә.
Әллә теләп, әллә теләмәстән,
Туктамыйсың инде, уйныйсың.
Кураенда өздергәндә башкорт,
Әллә ниләр шунда уйлыйсың.
Ә син уйныйсың да уйныйсың...

*1967*

## Тыйнаклык

Көн тынгач, кара нурлар ялганып төн тугач,
Яктылык, тибрәнеп, җиһанда эрегәч,
Җайлап, әй, күңелләргә моң сайлап,
Җибәрде сайрап сәхрәдә бер сандугач.
— Җырлама качып, җырчы, күрен,

сиңа ялан гашыйк! —
Дидем мин, моңнан арып, тәмам хәлдән таеп.
— Рәхмәт, кеше,
тик мине тәмамлыйсы җыр көтә, —
Дип, сандугач яфрак куесында булды гаип...

*1967*

## Авыл картлары

Күркәм сакаллары — уемтык,
Авыл саен калган ун бөртек.

Ике гасырга кан кордашлар,
Якты баганага охшашлар.

Мәдрәсәдә гыйлем иккәннәр,
Шушы җирне совет иткәннәр.

Үткән алар ун да бер сугыш,
Борылыш саен җиргә кан чыгыш.

Чеметә басып килә, җай гына,
Иңнәрендә ялтлый чалгылар.

Кызганса да тормыш мәрхәмәт,
Таза әле алар галәмәт.

Бераз яңа, бераз искечә,
Яши алар исе китмичә.

Чүәкләрдә сарут серкәсе,
Нинди матур авыл иртәсе!

Белә картлар — Коръән искергән:
Коръән хафиз булып ис кергән.

Карт булса да тырыша чамасыз,
Унҗиденче елдан чалмасыз.

*1970*

## Сибай

Тәүге кабат күрдем, шулай күрдем:
Тынны куырып барган суыкның
Зәһәрендә чатнап чәчкә аткан
Бакча сымак алга калыктың!..

Кинәт — гудок!
Гүя тальян җизе
Чыңгырдап коелды күректән, —
Бәс сарылган олпат аю төсле,
Электровоз чыкты рудниктан...

Сибай, Сибай!
Йә, исәнме-саумы!
Исәнмесез, дуслар, таучылар!
Таулар тетри.
Анда онытылмаган
Җырчыларның хәбәр тавышы бар.

Көннәреңә, төннәреңә кайтам,
Һәр тупсаңа кайтам, кадерлем, —
Учларымның кайнар куышында
Җылытырга сине әзермен!

Алларымда күтәрелә бара
Бакырүзәк булап-төтенләп —
Яфракларга чумган тургай сымак,
Шигыремә чума бөтенләй...

Таныйм сине, таныйм, эшчән тараф,
Йә, үт, йөрәгемә үт инде! —
Әнә күкләреңнең саф зәңгәре
Күзләремә сеңде бит инде.
Сибай, Сибай!
Матур да икәнсең!
Синдә хисләр иртә ярала,
Ярала да, балачакка кайтып,
Мәңгелеккә күңел кузгала...

Кышын күргән, шаять, җәен күрер.
Ак өметтә гомер итмәле:
Шаулап-җырлап үсәек без, Сибай,
Хөр яшик без, без яшь бит әле!
...Тәүге кабат күрдем, шулай күрдем:
Тынны куырып барган суыкның
Зәһәрендә чатнап чәчкә аткан
Бакча сымак алга калыктың!..

*1974*

## Ян!

Матурлыкка ашыкмыйча кагыл!
Әнә зәңгәр чыклар каелган
Сыйракларын, кузгалакка сөртеп,
Пакусларга төшкән каеннар...

Яфракларда йолдыз балга баткан.
Инде йолдыз түгел — атылчак*.
Янар таулар сүнеп калган мәлдә,
Тальян уйнар өчен алтын чак.

Колын кебек нәзберек пошкырып,
Нык оялып,
Гүя ялгаштан,
Тау булып тау,
Алсу баткак сөзеп,
Шифалы дым чүмерә Талкастан**.

Болытларның эремчеген сыксам,
Галәм сөтен бераз агызсам,
Һәрнәрсәгә җан өреп, шул сөтне
Тормыш каны итеп тамызсам,
Чамадан тыш якты булмас микән,
Җирдә яңа маяк кабызсам?

Җир-җиргенәм! Офыкларың дөрли!
Иңри таулар... Иңри уйсулык.
Юкка түгел бу сәер серлелек,
Юкка түгел мондый моңсулык...

Һәр кич саен офыкларга йөгереп,
Ут элдерсен өчен кылганнар,

Даласына Ак Пәйгамбәр булып,
Уяу торсын шигъри вулканнар...
Ян!
Яктыдан яктыракка өндә!
Ян!
Соңлама, төнгә көн сиплә!
Ян!
Йөрәгең итеп яшенгә бир!
Ян!
Көлгә кал, әмма су сипмә!

Шагыйрь авазы һәм дар агачы
Тәңгәл яшәп килгән тарихта
Үзенә-үзе җырчы хыянәт итсә,
Тылсым көче үлә тарлыкта...

Бер карасаң, миндә бар да төгәл:
Моңым төгәл, төгәл эчтәлек.
Алсу баткак сөзгән Ирәндектәй,
Бир, табигать, миңа нечкәлек.

Ызаннарга үлән сөрлеккәндә,
Ташлап аен — бирнә-бишеген,
Зөһрә төшәр, сорау алыр кебек —
Биксез тотам төнге ишегем...

...Матурлыкка каударланмый кагыл!
Әнә сыек зәңгәр каелган
Сыйракларын, кузгалакка сөртеп,
Пакусларга төшкән каеннар...

*1968*

## Җитлегү

*(Элегия)*

*Сибгат Хәкимгә*

Ашкындым чиксезгә — күгендә янды хисләрем,
Ә акылым, салкынаеп, җиргә инде.
Син ят иттең, мәхәббәтем, дөнья — читлек,
Син яр иттең — галәм янә чиксез инде.

Хөр табигать! Мәңгелеккә очкан җанын
Кай тәңгәлдә туктатырга тапмый форсат,
Хәлсезләнеп, җиргә чүгәм дигән чакта
Үз улыңа таянырлык урын күрсәт!

Башта уй бар, беркайда да әрәм булмам.
Бер чишмәмне күмдерделәр — исән елгам.
Ярты сүздә акыл иясен һич бүлмәм,
Буш акыл сатканнар өчен утка кермәм.

Мәхәббәтнең олысын йөртү җиңел түгел,
Ишетәсеңме, туган ягым, йолдызлы як?
Изге теләктә каңгылдый елгада казлар,
Яшенә тыгылып яктырта яшел маяк...

*1969*

*«Скрябин» теплоходы. Кама.*

## Өстә минем йөрәк кылын...

*Композитор Заһит Хәбибуллинга*

Җирдән, күктән куәт алып
Ташкан кеше,
Матурлыкны, телен табып,
Ачкан кеше,

Заһит Хәбибуллин, моңың
Җан җилкетә,
Сандугач җырын оныткан —
Синнән көтә.

Күңелләргә хуш киләсең,
Маэстро,
Күгең — кояш, баш өсләрең
Аяз тора.

Скрипкаң дүрт кыллы икән,
Исән булсын.
Өстә минем йөрәк кылын,
Бишәү булсын!

*1969*

## Кайтучы нотыгы

**1**

Өнсез калдым җылысын тойганда!

Туган ягым, кайнар яшем басып,
«Бу синме?» дип күңелем тулганда,
Ярсып кына лай, ярып бер сызгырдым,
Рәнҗетмәдемме дип куркып куйдым —
Танығансыздыр, урманнар!

Аклан читләрендә тасыр-тосыр
Күк гөрләпә уртлый боланнар шул,
Их,
Үзебезнең коба боланнар! —
Сезне сагынып кайттым, туганнар!

**2**

Тәрәзләре нурга буялган!

Якташларым, бу кем хәстәре, дип
Уй катмагыз иртән торганда —
Илгә кайттым, бик күп гөл ярattым,
Тәрәз төбе саен гөл тараттым,
Дымга тилмертмәгез, оланнар!

Күк гөмбәзе зәңгәр, гүя кызлар
Синке белән чайкап юганнар!
Синке белән чайкап юганнар да,
Их,
Киптерергә элеп куйганнар! —

Сезне сагынып кайттым, туганнар!
**3**

Җир шарына юллар уралган!

Каспий Өяземне бик юксына,
Неман сәлам әйтте Чоранга,

Күп халыклар күрдем — фәһем алдым,
Алар исәнгә — мин исән калдым,
Акылым аек кайтты Уралга!

Басуларга монда алсу көрттәй
Таң шөһрәте төшеп буралган, шул,
Димәк, кичтән изге юралган —

Сезне сагынып кайттым, туганнар!

**4**

Мачталарны кайчак сындырса да,
Зиһенем чуалталмады кара җил!

Йөрәгемдә җитмеш параллель!

Җитмеш параллельне бердәй сөеп,
Түбәдәге байрак өчен көеп,
Туган җиргә туры карый бел!

Йөрәгемдә җитмеш параллель!

**5**

Үлән ничек дертләп уянган!

Сезне сагынып кайттым, туганнар!

*1972*

## Кышкы фантазия

*Җырчы Илфак Смаковка*

**1**

Ай астында дөнья шундый якты,
Гүя галәм көмеш усаклык.
Усаклыкны егып учак яксаң,
Нурлар тигез төшмәс бу чаклы...
Гыйнвар, гыйнвар!
Ерып чыккысыз көрт.
Турыга юл яру бик кыен.
Карлар коры,
Изә басмасаң да,
Ифрат шәп шыгырдый ул быел.
Морҗалардан төтен — ак багана,
Кымшанмый да әнә, сак кына
Оеп калган
Салкын йолдызларны
Җирдән җылытып торган шәм сыман.
Ай асты дөньясы шундый якты,
Әмма көмеше инде үзгәрәк —
Таңга карап, тал тибрәтеп булмый,
Үзеңә хас илһам, көч кирәк...

**2**

Әнә айда — сез күрәсез микән? —
Чиләкләрен куеп як-якка,
Ай ташына күбәләктәй кунып,
Зөһрә,
Безнең Зөһрә кер чайкый...

Таң чаршавын юа...
Чаршау зәңгәр,
Буявынмы ыграк куерткан?
Изүе ачыла төшкән... Ашыгыпмы,
Яулык бәйләргә дә оныткан.
Ә йолдызлар игътибар да итми,
Шат тамаша кылып уртада,
Бурлаклардай, бер каешка җигелеп,
Таң чаршавын күккә тарталар...

**3**

Җырсыз калдык.
Ә син җырла, җырчы!
Дөнья сусау синең тавышка.
Күкрәгеңдә җирнең тарту көче,
Күк кодрәте тигез кавышкан.
Җырла, җырчы, гамең калтыратып,
Җырла давылда һәм силлектә.
Елмайтсаң да, синең хозурда без,
Елатсаң да, синең иректә...

**4**

Һаваларда сихри өн шәйләнә,
Хасил була чишмә агышы —
Көрт астыннан каз бәбкәләредәй
Бип-бип итә уҗым арышы...
Әлегә суык, дуслар, яз ул килер,
Араларны февраль бикләгән.
Көртне ачып сөяр идем, сезгә
Салкын тияр диеп шикләнәм...
...Ай асты дөньясы шундый якты,
Гүя галәм көмеш усаклык.
Усаклыкны егып учак яксаң,
Нурлар тигез төшмәс бу чаклы...

*1971*

## Динис Исламов истәлегенә

Әүлиялар, тыйнакайлар түгел,
Кыю ирләр иртә кузгала.
Менә тагын гәзитләрнең кайнар
Хәбәреннән утлы сумала
Йөрәгемә тамды...
Янам, янам!
Куйсагызчы берәр боз алып.
Бозлар эзләп, ярдан каен йөгерә:
— Үлде! — ди ул. —
Динис Исламов
Үлде! — ди ул...

Караңгылык көн яктысын йотты,
Керфегемдә — күңелем чыгы...
Шулай,
Әдәбият кояшының
Кителеп төште алтын ярчыгы!

Гадел усал, хәтәр гусар иде,
Шундый гусар — һәйкәл куярлык.
Шулай —

Ята.
Күкрәк тулы орден,
Чәчәк куярлык та урын юк.

Яралардан күккә ашкан бөркет,
Тик иҗатта тоеп бәхетен,
Һаваларга ашып ярсыды да,
Ярсыды да
Гөрселдәде җиргә —
Тар итмәделәрме ләхетен?

Кайда үлгән?
Кайсы якка карап?
Кеме булган башы очында?
Куркак җаннар өчен запас йөрәк
Калмаганмы аның учында?

Әүлиялар булып маташмады,
Кыланмыйча язмыш кичерде.
Гадел усал, хәтәр гусар идең —
Хуш, бәхил бул, абзый, хуш инде!..

...Өфем җирли.
Мин салларда агам.
Кариделдән тәүге сал куам.
Вак елгалар әле кузгалмаган,
Ә яр ишелә сулар саркудан...

*1973*

## Килеп чыгар идең...

Килеп чыгар идең — кызым чирли!
Кайтырмы, дим, наян, җор чагы?
Йортым чирли, бөтен нәрсәм чирли,
Чирли кызның хәтта курчагы...

Сырхаулы йорт утын басмый икән!
Яшел лампа янган өстәлне
Төн сагалый...
Гүя яшен сукты
Тәүге чәчкәм шыткан түтәлне.

Тау астында ал көрт күмгән өйнең
Тәрәзенә яткан чаганым,
Бозны эретеп, әле саумы, дигәч,
Үземә алдым сабый газабын.

Чү!
Кинәт җил!
Чаган эретеп баккан
Бојрага ай кереп утырды.
Утырды да минем тар бүлмәмне
Чыңрау моңнар белән тутырды!..

...Барыбыз да сау булырга тиеш!
Беләм, югалтып та табу бар.
Кыз бит исән, ник соң юксыну бар,
Әллә нинди бетмәс сагыну бар!

...Килеп чыгар идең — кызым чирли!
Кайтырмы, дим, наян, җор чагы?
Йортым чирли, бөтен дәүләт чирли,

Чирли кызның хәтта курчагы...

*1973*

## Күз сирпесә...

*Фәйзи ага Гаскәровка*

Тиңкер-тиңкер, тиңкер-тиңкер,
Тиңкәрәй, тиңкәрәй!
Каш астыннан сирпеп кенә
Кем карый, кем карый?

Безнең кызлар шулай карый,
Онытма, онытма!
Тәүдә үк елмайган караш
Сер тотмый, сер тотмый.

Сыгыла тирәк, сызыла йөрәк,
Курка тик, курка тик.
Бер кабынса гыйшык уты,
Үл дә кит, үл дә кит!
Юкны сөеп, бушка вакыт
Үткәрмәс, үткәрмәс.
Хагын күтәрер, нахагын
Күтәрмәс, күтәрмәс!

Кызлы йорт яңарта тормыш
Тугаен, тугаен.
Җир шарына бизәк хәтта
Бер каен, бер каен!

Биеп китсәләр такмаклап
Уенда, уенда,
Аяклар тыпырдый башлый
Урында, урында:
Кәр-рикә, ри-кәр-кә,
Рикәр-кумма, ген-нәем!
Кәри-кумма, рикәр-кумма,
Рикәр-кумма, ген-нәем!
Исә җилләр, сыгыла билләр,
Нәкъ камыш, нәкъ камыш.
Күз сирпесә, егетләрдә
Буталыш, буталыш!

Егетләр әмма күп сөйләп
Тормыйлар, тормыйлар,
Кыз ошаса, тәмугтан да
Урлыйлар — туйлыйлар!..

*1974*

## «Мендәрле Кул» чишмәсенә мөрәҗәгать

**1**

Төйнәлгәч тә чишмә булып, эзләп озак, син, илгәзәк,
Чишелгәнсең нәкъ шушында, табып монда баллы үзәк.
Ширбәтеңне таңда татып, су тургае күктә уйный,
Көне буе җиргә кунмый — сине көндез күреп туймый...
Монда гөлләр аеры үсми, монда гөлләр гөләндәме,
Кайгыңны кайда яшердең — үзеңдәме, үләндәме?
Инде сафсың, инде шатсың, карап бакса, башын иеп,
Кеше уйлар: «Аһ, бу тормыш гел шатлыктан торса!» —
диеп...

Васыятьләр бар, әтиләр юк, сөякләре кай җирләрдә?
Каберләр бар, әниләр юк — шомыртларда ак челтәрләр...
Әй, чишмәм, чишмәкәем, икәү түгел йөрәккәем,
Бар булганын сиңа бирәм, шулай иде өйрәткәнең...

**2**

Яшәүнең асылы — көрәш. Чикләрдә утны сүндерми,
Ил улы сазлык киптереп, чишмәсен ялгыш күмдерми...
Җирнең азат фикере өчен әҗәтеңне бүген түлә!
Фикердән курыкса шагыйрь, сүзеннән дә алда үлә.
Ватанымда чишмәләр күп, барысы да газиз, якын,
Ә син берәү — тәүге җырым тыңлады бит синдә халкым.
Еракта, офыкка карап, таш җылыткан төннәремдә,
Уянып, шат пышылдыймын:
«Мендәрлем... бар! Мендәрлем... бар!»

*1973*

## Финдлей

*(Роберт Бернстан)*

— Кем ишекне соңлап шакый?
— Әлбәттә, мин — Финдлей!
— Кайтып кит. Инде йоклыйбыз!
— Булмас! — диде Финдлей.

— Син килергә базнайт иттең?!
— Иттем! — диде Финдлей.
— Нәрсәдер эшләрсең тагын...
— Эшлим! — диде Финдлей.

— Сиңа ишекне генә ач...
— Бәй, ач! — диде Финдлей.
— Таңгача йокы бирмәссең!
— Бирмәм! — диде Финдлей.

— Өйгә генә үткәр сине...
— Үткәр! — диде Финдлей.
— Төнозын кунак булырсың.
— Булам! — диде Финдлей.

— Сине бер генә төн кундыр...
— Кундыр! — диде Финдлей.
— Гомергә тынгы бирмәссең.
— Бирмәм! — диде Финдлей.

— Безнең бергә булганлыкны...
— Бергә! — диде Финдлей.
— Берәүгә дә ычкындырма...
— Ярар! — диде Финдлей.

*1973*

## * * *

*(Роберт Бернстан)*

Арыш ерып кайткан чакта
Кичке ызаннан,
Күлмәген сыгардай булып
Дженни чыланды.

Кызкайга бик тә салкын шул,
Кызкай дерелди:

Итәкләр лычма су булды
Арыш эчендә.

Иген аша кемдер кемне
Чакырган икән,
Кемдер кемне кочкан икән,
Шул гаеп микән?

Безнең нинди кысылыш бар,
Ызанда әгәр
Кем белән кемдер арышта
Кич үбешсәләр!..

*1973*

## Тәрәз төбендә төн буе...

*Раузага*

Өязе буйлары вак тал,
Мин оя үрәм.
Тәрәзә аша чагылган
Сыныңны күрәм.

Үзең кара, кашың кара,
Чем-кара күзең.
Яратам мин караларны —
Бир, Ходай, түзем!

Челтәр пәрдәң ача төшеп,
Куйдың кыстырып.
Гүя «Кич чыгармыйлар!» дип
Куйдың кычкырып.

Әтиеңә сәлам тапшыр,
(Ишәйсен малы!)
Үзем әйтсәм, ишетелмәс,
Бүрәнә калын.

Җибәрмәсәләр аулакка,
Уенга тауга,
Берүк алай итмә, Рауза,
Болай ит, Рауза:

Имәнлек урманнарына
Шәфәкъ сарыккач,
Сеңлең түгел, үзең сөт илт
Бану карчыкка.
Әрәмәдә, буа янында,
Алырмын каршы.
Әйдә, бераз көтеп торсын
Гөлбану карчык.

Мин сине шулчак кочаклап
Үбәрмен генә.
Үбәрмен дә, синең өчен
Үләрмен генә.

Бар дөнья, үзен онытып,
Тынлыкта оер.

Кайдадыр кәккүк саташып
Кычкырып куяр.

Син сискәнеп тартылырсың:
— Аһ, озакладым!
— Иртәгә дә үзең сөт илт,
Сау бул, аппагым!..

...Тәрәз төбендә төн буе
Лепердәр тирәк.
Лепердәр җилләрдә тирәк —
Минем яшь йөрәк.

*1979*

*** * ***

Күкләргә карыймын. Күкләр якты.
Яктысында бераз кара бар.
Әллә ничек, көтмәгәндә генә,
Салкынаеп куйды аралар.

Яфракка карыймын. Яфрак яшел.
Яшелен өстәргә чама бар.
Яман күздән саклар вакытым үткән,
Яман сүздән генә арала.

Күзеңә карыймын. Күзең якты.
Анда ничек шикләр ярала?
Ваклап түбәнсетмә. Яраласаң,
Онытылмаслык итеп ярала.

Күк күкрәп тә болыт тарала —
Никтер моңсу шушы арада.

*1979*

## Каз йолкыйлар кызлар

Бипелдәшеп бәбкәдәй лә, тышта карлар тәңкәли.
Өйдә казлар, өйдә кызлар — керми китсәң, үпкәли.

Тупсагыздан эчкә үткәч, мамык кунды мыекка.
Ямьләсен казлар табынны, какланмасын кыекта.

Башланды каз өмәләре! Оча каурый иләккә!
Таушалмаган мәрмәр сыман, казлар ята беләккә.

Йолкый кызлар, каз йолкыйлар, бармагың чылатып ал!
Уч төбендә пар аккошның язган әманәте бар!

Бит очлары уймак чокыр, чокырлары алсудан,
Буянган алсу түгел ул, эчтә кояш балкудан.

Өйдә шау-гөр, өйдә шат җыр, хәлләре бетәр көлеп.
Бу мизгелдә шушы бер йорт җирне яктырткан кебек.

Ә эш кыза... Йолкыдыңмы? Мин йолкыдым икене.
Сул күз кабаккаем тарта — гашыйк булдым шикелле...

Казлар әзер. Әйдә, хәзер! Көянтәләрен асып,
Киләләр урамнан кызлар, кыр казларыдай басып.

Елга өстен яшь боз өргән — тәрәз пыяласымы!
Бозлы суда кул өшетми казлар юаласыңмы?

Кинәттән кызлар дерт итте, әллә күзгә күренә?
Егетләр җыр яңгыратты Шәрифҗан күпереннән:

«Ал тәгәрмәч, арт тәгәрмәч, барысы бергә әйләнә.
Без кызларга бәйләнмибез, кызлар безгә бәйләнә...»
Кызлар калырмы җавапсыз, аһ, алар тел бистәсе!
Егетләр сагаеп калды — бар икән ишетәсе!

«Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Галимҗан,
Сөюеңне үзем беләм, тик әйт, күпме жалуньяң?»

Егетләр — ялт, егетләр — шалт, елмаешып килделәр,
«Ә» дигәнче көянтәне иңнәренә элделәр.

Килештереп атлый алар, кызлар килә эргәдә,
Күреп калыйк дигән сыман, тартыла ак пәрдәләр:

Як-ягыңа өчәр каз да, көянтә саен алты.
Күңелле су буйларыннан шулай парлашып кайту!

Капка турысына җиткәч, кызлар: «Рәхим итегез!»
Егетләр инәлткән була: «Юк, кермәбез... Китәрбез...»

Үзләре ишеккә карый, үзләре инде тупсада,
Шулчак берсе морҗадагы төтенгә дә күз сала

Һәм әйтә, гармунын тартып: «Дөрләткәнсез учакны...
Егетләр, саныек эчтән — бу йорт ничә почмаклы?»

...Бипелдәшеп бәбкәдәй лә, тышта карлар тәңкәли.
Өйдә казлар, өйдә кызлар — керми китсәң, үпкәли...

*1972*

*** * ***

Адаштыра торган төн иде ул.
Дөнья йоклый. Аулак. Син дә мин.
Ай, чишенеп, елгада коенгач,
Озак чиртеп йөрде мандолин.

Моңланды ул, тыкрыкларга сугылып,
Урап чыкты тугай-чагылны.
Көтмәгәндә үзәгенә батты
Яшен суккан ялгыз каенның.

Йөрәк белән йөрәк арасында
Ара бетте. Тойгы төелде.
Син — минеке!
Шулчак айга кемдер
Корым яккан сымак тоелды.

Бер-беребездән котылырга теләп,
Бер-беребезгә ныграк тартылдык.
Без тартындык. Үзебездән түгел,
Намустан һәм айдан тартындык...

(Тәүге сөю! Ышанычың бөек,
Үкенечкә ярлар калса да,
Миңа гадел хөкемдар да идең,
Сүзсез кеше иткән Алла да!..)

Күр син, җаным, әнә тирә-якны
Нурга манчып, безнең каршыга
Корымлы кәүсәдән, кысыла-кысыла,
Шалкан сымак таза ай чыга...

Икеләтә зур һәм яшь иде ул —
Ә без шатбыз, бераз моңсу да...
«Аңлап бетеп булмый кешене» дип,
Ай озатты безне уйсудан...

Ядкарьләрне тапсыз булмый, диләр,
Мин ул тапны эзләп тапмадым.
Ул фәрештә булып кереп китте,
Чеметеп кенә ачып капканы.

...Чишелде таң. Ул да, миңа охшап,
Унҗидедә иде югыйсә.
Яңа буынланган колын сымак,
Өязедә таллар су эчә...

*1979*

## Чыны-шаяруы бергә

Бозылды көн — чәнчеп ява яңгыр,
Бозылды кан — түзәм җәбергә.
Яңа төзелеш пычрагын себергән
Җил
Үтәдән үтә бәгырьгә.

Вакыт күпме? Безнең вакыт күпме?
Ачудан күлмәккә ут капкан.
Кадалып ла китсен, дим, дөньясы,
Кулым салыйм кайсы ботакка?

Шулчак нидер баш очында гына
Гөлт кабынды — очкын очырды.
Афәт сизгән боландай, тасырдап
Сикереп үттем тирән чокырны...

Электр чыбыгының черт-черт көйрәп
Төшүен күргәч, миңа кот кунды —
Юктан гына һәлак була яздым,
Ярый, дидем, качып котылдым...

...Елап килә идем — көлеп куйдым.
Күтәрелде кәеф ничектер,
Фаҗигане тормыш көлке итте,
Үлем миннән көлеп кичекте...

*1980*

## Илсөяр кызым белән сөйләшү

— Айны урталай бүлгән кем кулы?
Яртысы кәләшенең мендәрен яктыртса,
Яртысы — киявенең киткән юлын...

*Вьетнам халык җыры*

**1**

Төргәндә сине биләүгә,
«Ал изгелегемне» дип һавада тонды юксыну,
Җиләс солылардан калыкты көмеш күләгә.
Син солы көлтәсе кебек йомры һәм хуш исле,
Иреннәреңне үбәм, алар нәкъ сөт өсте,
Син, кызым, яктылыкка туенган гәрәбә төсле!
Бирәвем, әмма берәгәйлем син!
Көттереп килгән җәем син!

**2**

Тормышның мин ике даһиен беләм:
Берсе — ут, без аны Аллалардан урладык.
Икенчесе — бала,
Икесе дә мәңгелек, икесе дә кешеләрне җылыта.
— Ыг-гы-ыг-гы...
— Тс, кызым!
Әнә күктә нинди матур ыгы-зыгы:
Баш очындагы оялчан апаең ул — ай,
Шомлы төндә
Йолдызларын тезгән дә,
Гөлдер-гөлдер,
Күгәрченнәр сулыгына су кереrgә илтә...
Без ничәнче буын? Җиңелме соң безгә?
Үзгәрә заман котылгысыз, төсе төшә йөзгә.

**3**

Вьетнам...
Зифа камышлыклар үзәнендә
Балаларым белән мәктәпләрем яна,
Гөрзи елан урталай бүлгән йөрәгемне
Менә ничә еллар
Үлем капшый.
Ах, минут!
Бу газаплардан соң кыргыйлана күзәнәк,
Куырыла тере орлык,
Хатыннар бәбәйли алмый!..

**4**

Балакаем, әллә нишләде дөньялар кинәт!
Коелыр канны тоеп,
Үксеп аунады күктә
Чарпакланган ай.
Төнен
Мәгарәсеннән качып
Киткән мин каһәрләгән дию.
Алга, көрәшкә, кызым!
Дәртем белән бүләк иттем сиңа тулы тормыш,
Яртысы аның — нәфрәт,
Яртысы аның — сөю.
Күзәт тирә-якны, йоклама, уяулык!
Кулыма кара, калтыранмый,

кулымда — кызыл яулык!

**5**

Сабыем!
Әтием мине истәлеккә дип
Тапшырган да Гүзәл Яшьләр Ширкәте —
Комсомолга,
Калдырмаган бүтән бернәрсә дә
Азатлыктан башка.
Көтте аны әни нәкъ 18 ел, —
«Кайтмады иртән, балалар,
Кайтыр, бәлки, — дип, —
Кичке ашка...»
Революция, кечкенә сабыем, дәвам итә һаман!
Килә ул һәр тарафтан, туа ул яңа заман!

**6**

Мине түземсезлек алга илтә!
Хыялымда туган аякларыннан алып өлге,
Мин,
күптән инде энҗеләр тезеп,
Сиңа гаҗәп җыйнак читекләр тектем.
Алар бик килешә сиңа,
Алар учымны алдамый,
Мең тапкыр кидердем, мең тапкыр салдырдым,
Үптем,
Тагы да үптем,
Бер күнлек гәүдәңне яңадан капшап чыктым...

Йөрәк җебен өзеп ала икән,
Йөрәк ярып ла чыккан бала икән...

*1968*

## Кайсыгызны юатыйм?

**1**

Мин сине ничек көттем, әти!
Кичләрен, өемдәге өчле лампаны сукырайтып,
Кабынганда якты йолдызлар күктә,
Яланаяк, болдырдан торып,
Үткән самолетларга оран сала идем:
— Әтине кайтарыгыз!
«...Менә-менә ачылыр мине зарыктырган ал парашют,
Чыгар аннан, шатлыгыннан шашып,
Хәрби киемле иң изге кеше,
Уң кулында — автомат,
Сул кулында бер буханка ап-ак икмәк тотып...» —
Дип торганда көтеп,
Шыксыз таулар,
Зиһенемне йотып,
Кабат-кабат кайтаваз бирде:
— Кай-тарыгыз!..

Миңа хәзер — 26.
Бөдрә солылар чәчемнән көнләште,
Баш очымда, дулкынланып,
Бер уч кылган калды.
Син кайтмагач, әти, боланнар да хәтта
Ачылыкүлгә килеп мөгезен салды.

**2**

Мин сине ничек яраттым, әни!
Хәтереңдәме,
Калмык далаларына чакыргач комсомол,
Язган идем аннан бер хат:
«...Улан-холлдан Каспийгача,
бер йотым суга сусап,
Чакрымнар санаганда, дуслар белән
Тап булдык бархан түбәсендә
Ал яулык кебек бер пар мәккә.
(Алар үсми ялгыз.)
Гаҗәпләндек, әни,
Бу җил туты белән көн күргән ком тереклеге
нинди сабыр...»

Юксынуларын яфрак итеп койган
Тирәкләр юлы буйлап
Алып килдең мине, солдатны, язмыш,
Күрсәттең яңа кабер...
Әниемнең каберен...
Суынмасын сукмак, туганнар,
бу изге йөрәккә,
Узгынчылар, ял итеп,
чәчәкләр салыгыз.
Тауларда калган тавышым
сезне куәтләр:
— Кай-та-ры-гыз! Кай-та-ры-гыз!

**3**

Гомерлек республикам — тауларым, урманнарым,
Сезгә сәлам!
Кышларын кышлап читтә,
Туган телен онытмаган кошларым,
Сезгә сәлам!
Кешекәем, ата баласы, яхшымы, начармы син,
Сиңа сәлам!
Бөек халкым, синнән башка уйларым сап-салкын,
Сиңа сәлам!
Киләм мин яшәргән җир буйлап,
мәһабәт бер Ятим,
Сагындым, бик сагындым үзегезне,
Йә, кайсыгызга җылы сүз әйтим соң,
соң, кайсыгызны юатыйм?
Изгелекне җырлау өчен,
җырчылар,
эзләмәгез зур сүзләр.
Бары юксыну ул, туганнар,
бары юксыну ул...

*1968*

# Мәхәббәтем турында монолог

*В-га*

**1**

Хәтереңдәме, кайнар иреннәреңнән синең
Беренче тапкыр үпкән идем?
Син шунда ук, шырпыдай чатнап,

Төн зәңгәрлегенә йөгереп кереп киткән идең.

Ә ак яулыгың
Иңеңнән очты да,
Һавада бөтерелеп-бөтерелеп,
Капланды җиргә,
Теләп ак бәхет...
Өязе-елгам, дулкыннарың шаһит.

**2**

Хәтереңдәме, тынлыкта йөзгән тауларга бәрелеп
Өч тапкыр кабатланды безнең аһәң:
«Мәңге-е бергә-ә-әү...»
Шулчак, бит алмаларың бәрхетендә эз калдырып,
Ике терекөмеш тамчысы тәгәрәде җиргә...
Куллар кулны кысты.
Кичләр кавыштырды,
Ә таңнарда,
Таңнарда булды
Мәхәббәтебезнең урак өсте...

**3**

Коенып нурда, тауларга ташландык.
Бу — пакь йөрәкләребезнең бәйрәме иде.
Ә күкнең зәңгәр җәймәсенә сибелгән йолдыз гаиләләре
Безнең өметләребезнең ачкычлары бәйләме иде.
Сайрадылар кошлар,
Кунып иңебезгә.
Гүя карт таулар уйнады курайда
Икебезгә, тик икебезгә!

**4**

Кулларыбыз белән ишә-ишә йөздек сөт диңгезендә,
Чалкан туган таза ай булды безгә көймә...
Сузылган идем көймәдән
Өзеп бирим дип бер тәлгәш йолдызлар миләшен,
Бушлыкта пышылдадың миңа:
«Торсыннар... тимә...»

**5**

Капчыгым асып авылдан чыкканда, үпкәләп калдың:
«Сине миннән башка кем саклар,
үзең белән алмыйсың», — дидең.
Илләр гиздем.
Яшь йөрәкләр союзы биргән адрес белән мин,
Җир кабыгын ярып,
Факеллар кабыздым,
Саллар агыздым.

**6**
Көчле идем.
Вулкан төсле,
Күкрәгемнән чыккан кайнар ләмнәр белән
Байтак кына хаталар да күккә чөйдем...
Ә соңыннан — нишлим? — ташка башымны бәрә-бәрә,
Җирем күкрәгендә үкси идем...
Чак сине югалтмадым.
Мәңге истә калыр:
Мәхәббәтнең килер кырауларын
Алдан күрү авыр.
Мин бу хакыйкатьне соңыннан гына аңладым.

**7**

Тормыш мине чакма ташы итте.
Ут кирәксә — кабынам.
Миемнең һәр күзәнәге — өлгергән йөзем.
Чакыру сигналларымны ишетеп тә хәбәрең булмаса,
Күк зәңгәрлеген танымый якты күзем...

Чәчләреңне сагынам.
Толымнарың — төнге су юлы!
Хуш исле ул — яңа чапкан солы...

**8**

Ал минем мәхәббәтемне.
Яшьлегем күгенең ал болытларында озак гизгәннән соң,
Ул үзенең корылмасын яшеннәргә бушатты.
Җылы яңгыр булып яуды ярмалы туфракка.
Гәрәбәдәй орлыкларны иркәләп уятты.

Шатлыгым атланган ак атымны
Беркемгә дә бирмәм.

**9**

Ташлап качса аты яуларда,
Нишли ала соң кыю ир?
Киленнәр тол калса тауларда,
Тын гына,
Тын гына
Ташларың елый бит, туган җир...

Еллар ераклыгында хисләрең саекса,
Кызганма мине. Калдыр.
Сиңа тугрылыклы булып бер нәрсә —
Сулмас мәхәббәтем калыр.

*1965*

*** * ***

Әле яктырып бетмәгән,
Агачлардагы айлы бәс тә яктыртмаса,
Булыр иде тәмам караңгы!

Тукталышта трамвай көтәм,
Кочагымда ике яшьлек кызым да трамвай көтә,
Ул хәзер ни дисәң дә дәүләт күләмендәге кеше бит —
Балалар бакчасына йөрүче гражданка,
Ә алар, беләсез,
Кулларындагы кашык белән дәүләткә нык якыннар.

Бераздан ике ут йомгагы пәйда була,
Алар якыная,
Менә озынча кабакка охшаган нәрсә
Куллары белән һавадагы чыбыкларга тотынып
Килеп туктый,
Туктый да, кызымның песие сымак,
Күзләрен челт-челт йомып,
Керфекләрендәге бәсне коя һәм ишекләрен ача...

Ә тукталышта — тугыз йөз дә туксан тугыз кеше,
Берәүнең дә торып каласы килми,
Этешәбез-төртешәбез һәм барыбер
«Кабак» эченә керәбез.
Анда якты һәм җылы,

Кызым исә тынгы белми, үз телендә сорый да сорый:
— Әти, ай кайда булды?
Әти, ай кайда булды?

*1975*

## Кавказ

Кул яссуы белән ипләп кенә
Алсу томаннарың тараттым.
Таң вакыты икән;
Мин дә сине
Таң вакыты булып яраттым.

Күрдем —
Синдә ике кояш яна.
Ике хәтер көйри. Ике наз.
Нидер күкри. Нидер белеп күкри.
Сиңа охшап күкри ул, Кавказ!

Бу — саф аваз ярадан ярала.
Исемлектән төшкән вулканнар
Терелә кабат —
Бүген таңны шакый
Теге дәвердә сез кылганнар...

Тора Казбек —
Ак аты Кавказның.
Куркуның юк анда тамчысы.
Гүли, үкерә аста Арагвиның
Ак күбеккә баткан камчысы.

Үзен-үзе кыйнап чаба Казбек,
Әмма үзен узмый — коты бар!
Кул яссуым белән күкрәгеннән
Бер уч көлен алдым — уты бар!

Кавказ, Кавказ!
Әбием әкиятләре —
Каф тавының күкшел катлавы.
Синдә сыман ишетәм Уралымнан
Хафизаләм-иркәм* атлавын.

Әй, табигать, әй, эчкерсез киңлек,
Бер хәйләсез көчең бушана.
Бер хәйләсез ышаныгыз, таулар,
Мин бит сезгә ифрат ышанам.

Якыная барган саен кояш,
Салкынайта...
Ә күк — яктырак.
Ташкын нурдан күзе томаланган
Дөнья ята бераз аптырап.

Бар кояшның сукырайту көче.
Яктының да бар үз чамасы —
Биектә югалткан күзен эзли
Түбән төшкән бөркет баласы...

Кавказ, Кавказ!
Зәңгәр карларыңнан

Яланаяк — чыкмас ислəрдəн! —
Таң — сылу кыз — ашыгып букет җыя
Югалырга торган төслəрдəн.

...Кул яссуы белəн иплəп кенə
Алсу томаннарың тараттым.
Таң вакыты иде... Мин дə сине
Таң вакыты булып яраттым.

*1979*

## Өзелгəн кыл

Сабыр итмə, заман, талəп ит син:
Гакыл килə җырчы эзеннəн.
Эол арфасында* җил туктаган.
Арфа өнсез — кыллар өзелгəн.

Гомер бакый сиңа җəяү менеп,
Менеп җиталмаган кешелек,
Мəгъшук**,
Бүген түбəндə — хəрчəүнə,
Тора күзгə кергəн чүп кебек.

Тау түбəсе — хəтер.
Сиңа, Мəгъшук,
Мəгънəсенə ирек хисенең
Күтəрелгəч,
Ачыла биеклеге,
Түбəнлеге һəрбер кешенең.

Бəхеттəн дə, тəхеттəн дə читтə
Торган җырчы
Ерак якыннан —
Йөрəк руднигыннан, ялкыннан,
Тəгəрəтеп кояш чыгаргач та,
Җофар сыман ыспай, сак кына
Үтерүче чыга яктыга...

Менə барьер.
Кан дошманың бар җир.
Күкрəк куеп мəкер угына,
Еш кына — юк, ышанасы килми! —
Рухы белəн көчле
Егыла...
Күпме алтын калды саф алтында?
Күпме атом бар соң атомда?
Күпме дус бар дуслар арасында?
Күпме халкың калды халкыңда?

Тəүбə итмə, кеше, хыянəттəн соң,
Кыл ялганмый намус артында.

Җиңелүме бу?
Бəлки, мөртəтлəргə
Кул күтəрү кирəк түгелдер?
Дуэль — мөһим.
Ачык дуэль мөһим,
Вакланмасын өчен күңелләр.

Егыла үзенең ялангач кулыннан
Иленə кояш биргəн баласы —
Таң рəшəсе белəн яба Мəгъшук
Россиянең канлы ярасын.

Егыла җырчы, азатлык мəгъшугы,

Сатылмыйча, алыш-бирешсез.
Әй, пәйгамбәр-шагыйрь, син — Мәгъшукны,
Мәгъшук сине итте үлемсез.

...Туган илем!
Шаулы төзелешеңдә
Мөртәт очрый — үлми, үтерми.
Дуэльләр юк. Пистолет сатылмый.
Мөртәт хәзер дөрес фикерли.

Сабыр итмә, илем, таләп ит син:
Гакыл килә җырчы эзеннән.
Бу арфаңны син миннән төзәттер —
Өнсез бит ул... Кылы өзелгән.

*1979*

## Татырлы сулар

Монда кояш, акылыннан шашып,
Көне буе күктә типтерә —
Кызган ташлар туып өлгермәгән
Томаннарның яшен киптерә.

Гади нәрсәләр дә гаҗәп монда:
Көн эссесе бумый алкымны.
Иң татлы су монда — татырлы* су,
Учта саклап була ялкынны.

Монда таулар, итәкләрен җыеп,
Күктән йолдыз өзгән тәңгәлдә,
Коман-елга**, безнең тарих сыман,
Кире комга сеңгән гамәлдә,
Эльбрус сыртлары пычак булып
Ертып чыккан җирдә уйсудан
Ага,
Гүя йөрәк ташы аша
Татырлы су... Татырлы сулар...

Йөрәгемнең яраларын юам,
Шул суларда җаным сугарам.
Тезгененә басып үзәннәрнең,
Мин тауларның атын тугарам...

Таулар-атлар, кая ашыгасыз?
Чиксезлеккә җитәр сөңге юк.
Азатлыкка тигез азатлык юк,
Тынгы эзләгәнгә тынгы юк.
Нигә шулай сөям икән сезне?
Нигә сезне күрәм иң элек?
Тигезлектә кайнар тиз суына,
Бик тиз төчеләнә изгелек.

Төчеләнә күрмә, тозлы чишмәм!
(Төчеләнә хәзер диңгез дә!
Бар юньлеләр трибунасын бирсә,
Трибунаны яулый юньсезләр.)

Тарлавыклар белән тәртә каерып,
Таулар җигеп кайтасым килә! —
Айныймын да —
Ташка чәлпәрәмә
Чынаяклар ватасым килә...

*1979*

* * *

Заман, минем белән ни кыласың?
Сузган балың — алтын авызлык.
Бу тормышта кайчак били мине
Корыган фонтан сыман ялгызлык.

Гади түгел, серле юлдан көн-төн
Дары комын төйгән Пегасым,
Йөрәгемнең төененә төшеп,
Алып чыга фикрем кояшын.
Алып чыга хәтәр тарлаулардан —
Алларыма ташлар ишелә.
Мин ашыгам. Берүк туктатмагыз,
Мин сөенеч илтәм кешегә.

Күрәм, әнә Канәгатьлек Титаны
Кочакларга килә каршыма.
— Ягылма! — дим. — Мактап та йоклатма.
Көрәшик без. Мә, ал тастымал!

...Йомшакка басам дип киң елмайсам,
Табаныма энә кадала.
Заман мине шулай иркәли дә
Шулай илһам белән җәзалый.

*1980*

## Биштау белән хушлашу

...Сәфәрләргә чыгар чак җитте.

*Р. Мифтахов*

**1**

Нәрсә биек, даламы, таулармы?
Кемнәрне кем килә җитәкләп?
Буш бәхәстә без иртә картайдык,
Ә хакыйкать һаман итәктә.

Язмыш биек!
Җирнең карынында
Кузгалгач дәһрилек утлары,
Биштау булып күккә ашкан дала
Биш өлгесен күкнең куптарып!..
Сау бул, Биштау! Синдә үзем салган
Эз күрәм дә, төшәм коелып —
Бездәгечә уйный Каф тургае,
Бөтнек тузанында коенып.

Туглана әнә тауда болыт,
Туглана куе зәңгәр төс.
Гүя кымыз шашып кабара да
Ташып чыга тышка яланөс.

Чын гүзәл, син һәрчак хәвефлесең!
Күгүләннең күкшел төтене
Аша чәчәп, кемдер сорый сымак:
«Бар әгъзаларың да бөтенме?»

Нинди өн бу?
Бәсле ташларыңның
Күзләренә текәлеп карадым —

Гүя, Биштау, энә күзе аша
Үттең унөч гасыр араны...
**2**

Булган заман: яралган — таралган.
Ярым-йорты йортлар-учаклар.
Аттиласыз калган ярым һуннар,
Бүген исә ярым кыпчаклар.

Иртәгәсен бу кайнар кан ыруг,
Калганнарга түшәп моңнарын,
Арал-Команнарда дәүләт кора —
Кубрат ханның Бөек Болгарын...

Кем нәселгә яла яга, мәлгунь?
Кем йортына өмет югалткан?
Карый, бәгырь аша үтә карый
Кылчык каш астыннан Кубрат хан.

Кем үз шәүләсеннән үзе шүрли?
Ә кем артык батыр кылана?
Таманча бул. Әгәр булалмасаң,
Син йә даһи, йә бер дивана.

Кеше арасыннан кеше эзләү —
Хәтәр һөнәр (түгел язык та!) —
Җирен уйнап саткан тасма телнең
Уйлы башы эленә казыкка.

Килә бәла!
Кубрат үлеменнән
Киң офыклар сүтелеп тарая.
Тәхет өчен ызгышта ил бөлә,
Басып керә илгә кара яу.
Гарьлегеннән ай акылдан яза —
Ул да кеше өчен ояла! —
Һәм ак салган бозау күзе сымак
Тишелеп ага... тиле дөньяга!
Кайда сез, бердәмнәр?
Өзелә дә
Язмыш булып өмет терелә.
Бәлки, без бер җырсыз калыр идек,
Шытса әгәр шулчак бөреләр.

Изге сәгать суга — таркала ил.
Кафтау итәгеннән Дунайга
Кузгала бер ыруг; икенчесе —
Идел-Чулман буе, Уралга,
Өченчесе, һәлакәттән качып,
Чигенә артка, төпкел-тирәнгә.
Куркаклыктан түгел. Шулай да...
Туглана түбәләрдә сөрем,
Тугланып кайный көрән төс.
Сөремен чишеп ташлап, тораташны
Кочар сымак ялкын яланөс.
Тамак төбен ертып акыра дала.
— Кал, бала, кал! Яшә, абайла! —
Ил атасы белән арка терәп
Хыянәтче бара арбада.

Укылмаган иске китап сымак,
Учак сүнәм дигәч талпына.
Күчеп барган ярым күчмә кабилә

Баш очына яңа ай куна
Урак булып...

**3**

Каф таулары!
Исемегез белән
Халкым әкиятләре яктырган! —
Сине таныйм. Таныйсыңмы, Биштау?
Таныйсыңдыр... Без бит — бертуган!
Сөйләмәдем бу кыйссаны бары
Тарих өчен шигъри калыпта —
Мин таң калам: ниләр генә күрми,
Нинди хәлгә төшми халыклар —
Язмышында! Алышынса җир-су,
Алышынса да потлар, аллалар,
Үткән өчен Алла җавап бирми,
Җавап бирә икән балалар —
Ә халыклар туган калалар.

Евразия киңлекләрен кичкән
Гөл таҗының бер үк элпәсе —
Без исән-сау. Безне давыл алмый.
Без бит Бөек Туран иркәсе.

Биш бармагым кебек Биштавыма
Бәрелеп ярсу җилләр егыла.
— Хуш! — димен дә тагын кул селкәем,—
Хуш! — димен дә яшькә тыгылам...

*1979*

## Кафтау язы

Караңгы. Яңгыр. Таулар да карадан коелганнар.
Кошлар аваз салып куя куркыныч тоелганга.

Агачлар яфрак яралмый. Ботак аерыларында
Эчәкләре эленеп тора чечен балаларының.

Хаҗи Моратның киселгән башы Кафтау кырыннан
Бүген карап тора безгә тишек күз чокырыннан.

«Алты мең биш йөз егерме беренче» саны белән
Бу баш егерме беренче гасырга килеп килә...

Баш кисеп туймаганнар, тиресен тунаганнар,
Спиртка салып куйганнар, качар дип уйлаганнар.

Азәрбайҗанда — гәүдәсе, Питерда, базда — башы,
Баш белән гәүдә шул көннән кавыша алмыйча яши.

Бу кадәр дә «изге» җанлы булыр бу урыс, ай-бай,
«Тынычлык хакына» диеп чукынып ята, һай-һай...

Тауларга тәре эләләр Илбарыс-тауга тикле,
Кафтау буйлап тәре элеп йөри Алексий Ике.

Кайнар чишмәләребезгә чишенеп кереп ятып,
Аракы эчәләр алар, автоматлардан атып...

Сайрамый сандугачлар да, акылдан язган бугай.

«Безгә тимиләр әле», — дип калтырый чаттан нугай.

*2001*

## Өязе

Уң ягыңа текә тау тезгәнсең,
Гүя пәке белән уйгансың.
Тау текәңне, нәкъ әлифба сыман,
Ак таш белән йөзләп куйгансың.

Өязекәй!
Синме дәрья түгел?!
Вак дулкын каксаң да таллыкка, —
Дәрья гынамы син? — Диңгез булдың
Диңгез күрми үскән халыкка.

Челләләрдә көйсәләр дә, сине
Үзенә бормый Нәҗип, Хәсбиләр, —
Дим, Агыйдел аша ясак итеп
Озаталар сине Каспийга...

Өязекәй!
Илкәй!
Нечкә билкәй!
Бөгәлләрең көләч бөгелә.
Дулкыннарың минем йөрәгемнең
Алтын алмасыннан түгелә...

Аһ сез, таллар!..
Тамчыланып тамган
Һәр яфрагы саен сандугач.
Яфрак терелеп, тынычлык кошлары
Монда кайнап, ал таң кабынгач,
Тыңласа, дим, бар дөнья бу моңны,
Бәлки, низагларын кинәттән
Онытыр да, берләшер иде, дим,
Бигүк дус булмаган милләтләр...
Өязекәй,
Яшел беләзеккәй!
Тауларыңның тыны тезгендә.
Оялма көчеңнән. Тыйнаклыгың
Болай да чагыла көзгеңдә...

...Офыклары белән туа кеше.
Офыклары чиксез сөйгәннең.
Талларыңа чуклы йөгән элдем,
Син саклый күр минем йөгәнне...

*1982*

## Миләш

Кара кырау суккан яфракларын
Чак тирбәттем —
Саф моң түгелде.
— Әйтче, миләш, акмы үзәккәең?
Әллә инде ак та түгелме?

— Әлегә ак. Мин әҗәлдән һәрчак
Моңнар гына түләп котылам, —

Диде миләш. —
Җыр җырлаган булып,
Мин әле зинданда утырам.

*1979*

## Кичке җайдак

Ат чаба. Дүрт тоягыннан
Дүрт давыл күтәрелә.
Давылларда йолдызланып
Яналар күзләр генә.

Аргамакның колаклары
Тырпаешкан чук сыман.
Ялына сыланган җайдак
Җәядән чыгар ук сыман.

Дүрт давылдан дүрт арканга
Уралып алып җайдак,
Камчылый атын һәм үзен,
Һич кенә тормый сайлап.

Ат керфегеннән тәгәри
Ямь-яшел күз яшьләре.
Тояктан оча очкынның
Тәлгәшле миләшләре...

Төнгә каршы кем ашыга?
Нигә ашыга икән?
Дуслары каршылар микән?
Дошман камчылар микән?

Шундый мизгел, йөрәк сизгер!
Көндез йә төнлә түгел,
Кичке шәфәкъта шартларга
Җилкенә гашыйк күңел.

Гөлемгә — үргә чаба ул,
Түбәннән — Кәркәледән.
Йөрәге тарихка керә —
Чак-чак түзә әлегә.
Аргамак канатларында
Хөрмәтле вә гыйззәтле
Йөк бар, ул йөк гыйшык хаты,
Өзә торган үзәкне.

Хатта шул: «Мин хисләремне
Тел белән әйтә алмыйм.
Мин синсез ятим, Хәмдиям,
Мин синсез яши алмыйм.

Бүген миңа йөрәк әйтте:
Барып кил аңа, диде.
Аның да һушы сәламәт,
Йөрәге яна, диде.

Өйләнә калсаң, аңардан
Башканы алма, диде.
Эшкә — калсаң кал, сөюдә
Син соңга калма, диде...»

...Дүрт давылдан дүрт арканга

Уралып алып җайдак,
Камчылап чаба...
Таулардан
Ай чыгып килә җайлап...

*2001*

## Кайту

Каенлыкка җитәм... Карсылулар
Көлешә-көлешә гүя кар шуа —
Һәр каеным, шампанский ачып,
Ак күбектә килә каршыма...

Торып калам күбек дәрьясында,
Туган авыл, мине тартып ал! —
Җир шары зур. Әмма синең генә
Мине тартып алыр шартың бар.

Әй, Кәркәлем, юкәң — кәрәзле бал,
Кымызлыкта кымыз өлгерә.
Көчегең дә юлдан премиаль
Сөяк көтеп алга йөгерә...

Авыл, авыл!
Киткәнем юк синнән,
Кайтуым да шуңа үзенчә —
Өйләреңә мин балкыплар керәм,
Уч төпләрем кайнар көенчә...

Әнә күршем Вәкил тыкрыгыннан
Чабыртып чыккан да кычыткан:
— Рәхәтләнеп чагып калыйм әле, — ди, —
Сирәк кайтасың бит, чукынган!

Бар гадәтем, авылым, синнән килә:
Бераз җитди, бераз кызык та,
Бераз моңлы, бераз гына серле,
Бераз гына чирле сызыкта...

Картаяммы? Нинди куркыныч сүз!
Мин гөлләргә таба үреләм.
Үреләм дә бер читкәрәк басам —
Читтән чибәррәк күренәм.

*1981*

## Талант турында баллада

*Таһир агай Ахунҗановка*

Берлин — көлдә...
Прагада — дошман.
Кирегә ага сымак Влтава.
Барлык йолдызларны сүндерсеннәр —
Җиңү барыбер үзенә юл таба.

Моң да, Җиңү сымак, пар канатлы —
Анда — нәфрәт, анда — ярату,
Яраланган саен нечкәрә моң,
Шуңа күрә дә бит талант ул.

Уйный талант Влтава ярында,
Сагышланып талый тальянын.
Тальян телләреннән канап ага
Сугышның нык пешкән баланы...

Милли моңнар,
Имгәнмәгән моңнар!
Камалышта да бит тере сез.
Яшьтә кайрап,
Кылыч суза сиңа
Димнең һәрбер ятим бөресе.

Яшәр өчен туган көмеш тальян
Көлеп кенә карый үлемгә.
Ул — комиссар,
Ертык күкрәк белән
Приказ укый соңгы һөҗүмгә.

Арткы сызыктагы «катюша»лар,
Алгы сызыктагы танклар,
Пехотадан алда,
Моңга төренеп,
Талант белән тальян калыкты.

Ант талантка тигез. Ахры, шуңа
Син, билгесез солдат, исемсез —
Дошман сиңа ата. Үзенә тия.
Дошман үлә. Син бит үлемсез.

Йөрәгендә аһәңле ут булса,
Юкка чыкмый — җырга ялгана.
Тездән канда —
Ядрә ертып үткән
Тальянны ямый кансыз замана...
...Берлин азат.
Прага да азат.
Ярга чүп-чар кага Влтава.
Ышанмаслык түгел: Җиңү сымак,
Талант барыбер үзенә юл таба.

*1980*

## Хәтерләү

Таш юл.
Телеграмм баганасы,
Кеше сыман сөрлегеп,
Чыбыкларын өзгән,
Ярты гәүдәсе белән
Инде җиргә сеңгән, бахыркай!
Ә чынаяк колаклар шомраеп
Тыңлый кичәге көнне!

Ачлык һәм кояш.
Борын тишекләрендә кызган тузан.
Ә син
Барасың да барасың...

*1983*

## Алтын тәңкә җыры

Бер халык күрә — исләми*,
Бер халык күрә хата.
Кем елый? Мин исә ялгыз,
Тузанда җырлап ятам.

Мин алтын, әмма бай түгел,
Байларның сере саран:
Алтын баш кисәр кылычны
Тимердән коя һаман.

Казнадан качып, кызларның
Толым чулпыларында
Чыңладым — чыңлап өзелдем,
Моң алдым шунда гына...
Вакытында өзелегез,
Өзелү мөһимрәк.
Мине каплаган яфрак та
Өзелеп төшкән йөрәк.

Акча санаган уңайга
Йөрәк моңнарын сатып,
Күзен кан баскан «абзыйлар»
Үтәләр мине атлап.

Яратам яңа таңнарның
Үзгәреп килешләрен.
Калмасын иде йөрәкнең
Янмаган өлешләре.

...Бер халык таный — ышанмый,
Бер халык таный хата.
Беркемгә кирәкмәгәндәй,
Тузанда аунап ятам.

*1988*

*** * ***

Йолдызларда сәгать ничә икән?
Бездә, җирдә, төнге унике.
Ялгышамдыр. Күпне белмим. Беләм:
Намусым бар, халкым, синеке.

Гыйлем эстәп, бар әдәптән читтә
Айга җылым салган бу җиһан,
Йолдызларны тибеп төшергәнгә,
Ахры, язып килә һушыннан.

Карурманда тудым. Йолдызлыкта.
Чыкмыйм. Юлы бардыр — эзләмим.
Карурман хакына сәҗдә кыйлып,
Ямау сорый ап-ак тезләрем.

Кеше, нигә айга менгән булдың?
Йолдыз кирәктеме, тәкәббер?
Чәчкә җитмәдеме — бер канәфер?
Кадер җитмәдеме — бер кабер?
Карурманның черек төпсәсендә
Төнен янган йолдыз ямьлерәк.
Бу ут черек йөрәкләргә кунган
Алтын йолдызлардан мәңгерәк.

Нигә кирәк ул җыр — җырламагач?
Нигә кирәк мәзәк — көлмәгәч?
Ник көләргә — карурман эчендә
Йолдызлар вакытын күрмәгәч?

*1988*

## Басуда

*Газиз Вафинга*

Җәйләр әйбәт килде...

Җылы яңгыр
Ява иртән, ява кичләтеп.
Шундук кояш-кода килеп чыга,
Тәгәрәтеп баллы мичкәсен.

Быел кояш бик тә иркәләде —
Кулдан гематоген ашатты.
Әлифба күтәргән сабый сымак,
Башак баскан әнә сабакны...

Кайда бакма иген дулкынлана,
Бал исләре аңкый һавадан.
Башак сөте белән яраңны яп,
Җир сулышы белән дәвалан.

Һәрнәрсәдән сусыл сафлык бәрә,
Һәрнәрсәдә тыныч иркенлек.
Басудагы маза гомерлек тә,
Иркенлекнең гомере бер көнлек.

Яшел башак! Синсез — әлифбасыз!
Тамыр синсез иртә картая.
Бары син тулышкан мәлдә генә
Җир күчәре безгә янтая...

Үз вакытың белеп саргай, башак.
Сагайма да, агай сагайсын.
Пәһлеван бул. Әйдә, сине үлчәп,
Гәзит бите генә саргайсын...

...Кояш, яңгыр белән эссе салып,
Ак мунчаның ташын кыздыра.
Әрлән күптән уңыш сызыгында,
Оясыннан чыгып сызгыра...

*1983*

## Шигырьгә үтенеч

Атын-алтын калдырмаган әти,
Похоронка бары калдырган.
Әни исә:
«Нәҗми үлмәс!» — дигән.
Похоронканы да яндырган.

Морза улы түгел, крепостнойлар
Минем өчен иген икмәгән.
Таулар мине, ачка үлмәсен дип,
Балтырганлы Кулга бикләгән.

Жуковский, Державиннар өйгә
Килеп йөремәде үскәндә;
Җиде яшьлек сабый, кәҗә имеп,
Тузан эчеп көтү көткәндә,
Миннән моңлы җырлар җырлатты да
Тукай агайларга алмашка,
Кояш үзе, чыбыркы шартлатып,
Алып менде мине Парнаска*...

Мин Парнасны күрдем — шарты катгый,
Әмма Парнас миннән уңмады.
Җырлап яшәргә тик хыялландым,
Җырлап кына яшәп булмады...

Заман миңа: «Талант — шартсыз, — диде. —
Пегас** ярсый сабан тартканда».
Шигырь яздым эшкә барган чакта,

Шигырь яздым эштән кайтканда.

Җирем, халкым!
Үләнем, игенем!
Артка этеп юк-бар юрауны,
Бертын белән тамагыма алдым
Сезгә диеп төшкән кырауны...
Ун гаделсез дан-мал бүлешкәндә
Бер гаделне яклап калыктым.
Заман, диеп,
Иман, диеп, Парнас,
Мәңгелеккә синдә карлыктым...

Ә шигърият өчен плебейлар юк.
Ул, хәерсез, белми кызгану.
Чәчкә күзләвенә тамган чык та
Чык түгел ул... Ул да — сызлану!

Замандашны, шигырь, ике әйлә:
Таң атканда, кояш батканда.
Күңелен күтәр эшкә барган чакта,
Юат аны эштән кайтканда.

*1983*

## Онытылган сүз турында баллада

Көн сүрелде. Ташлар җылы әле.
Көтү төште таудан, чаң коеп.
Башмак кайтты. Һәүкәш кайтып керде,
Ачылган капкага чак сыеп.

Көчекнең дә күз ачылган икән —
Катык кымтый калай савыттан.
Әтәч тирәсендә өерелә
Бәбәй итәк кигән тавыклар.

Мунча тирәсендә кычытканнар
Зәһәрләрен чәчеп утыра.
Ир нәрсәдер корыштырган була,
Өйгә керми — хатын котыра...

— Кеше ирләреме? Кеше ирләре
Көрәп кенә ала акчаны!
Ә минеке алтмыш тәңкә өчен
Ат тизәге көри, корчаңгы!
Адәм булсын, диеп, Ыртыеста*
Тракторга укытып кайтардым.
Йә, әйт инде, күләгә чебене,
Кәнүшнәйдә ниләр майтардың?

Кызды хатын. Калмады бернәрсә:
Арба. Ярма. Талак бизләре.
— Кеше ирләреме? Әт-тә-тә-тә!
Әт-тә-тә-тә, кеше ирләре!
Ат дигәннән...
Хатын дөрес сөйли —
Балачактан атка бәйләнде.
Ат дигәндә җанын фида кылып,
Җир читенә барып әйләнде.

Бригадада алар күп тә түгел.

Тракторлар аттан күберәк.
Хәзер җирдә, дөрес, яктырак ул,
Әмма күктә йолдыз чүплерәк.

Атта туды, атта үләр инде.
Әле үзе исән чакларда
Совнарком калдырган паек итеп
Яшел солы чабып кайтара...

Ә хатынга килсәк... Һәйбәт кеше!
Тик көяләк* — юкны уйлый ул.
Шәүләсеннән өреккән ат сымак,
Тигез генә җирдә дулый ул...

...Озак йөреп кавышмады алар.
Димче Дим кичмәде ун кабат.
Солдат әйтте: «Киләсеңме, Сәрви?»
Сәрви әйтте: «Киләм, Мөхәммәт!»

Өйдә савыт-саба шалтыраса,
Сиздермәде алар һичкайчан.
Елмайдылар.
Авыл гел сокланды:
«Вәт бәхетле гаилә, ичмасам!»
Балалар да, шөкер, үсеп килә...
Ана, олы кызы — иркәсе,
Шабырдатып сыер сауган була,
Ташып китми микән бидрәсе?

Нәкъ шул чакта урамнан, сөйләнеп
Килеп керә бригад кассиры:
— Кеше ирләре әнә, тырыш булгач,
Ел да ике сыер асрый!

Кеше ирләре дөньясын гөл иткән,
Кеше ирләре — кара тирләре!
Кеше ирләреме? Әт-тә-тә-тә!
Әт-тә-тә-тә, кеше ирләре!

Хатын ведомость суза. Акча саный.
Иркәй аны-моны белешми:
— Кирәкми, — ди. —
Иртән Сәрви алыр.
Кичтән акча санау килешми...

Шулай ди дә, карлыганнар аша,
Эңгер зәңгәрендә коенып,
Үзе белән иңендә күтәреп
Айның утырып туган колынын, —
Ул тупсага үтә... Менә ишек...
Моңсу гына өйгә керешли
Туктала да:
«Бар нәрсәбез җитеш.
Әтнәке, — ди, — нидер җитешми».
«Нидер» дигәч, нидер жу иттереп
Телеп ала йөрәк түреннән...
Нәрсә соң ул «нидер»?
Үле? Тере?
Әллә үлеп, тере күренгән?
...Ялт кабына дөнья. Яшьлегендә
Калган аты гүя пошкырды —

Ат өстеннән гүя, йөрәк ярып,
«Яратам!» дип кемдер кычкырды...

«Яратам!»
Аһ, бу бит онытылган сүз!
Әйтелмичә калган беркемгә.
Таш капчыкта картайган тоткындай,
Инде чыгасы килми иркенгә.

Бәлки, сөю һәркемдә булмыйдыр —
Аны бары уйлап табалар?
Бәлки, сөю һәркемдә чиксездер —
Тик чамага җитми чаралар?
Бәлки, сөю бары шыткан орлык —
Бер яңа гөл уртак тармактан?
...Ай гөлгеле* һаман бармак имә,
Һаман төер үтми тамактан.

Өйгә керә. Зәңгәр тәрәз аша
Әйтә айга:
«Шулай юрадым:
Миннән сиңа тик бер адым булса,
Гомер иткәнемә — мең адым».

*1983*

## Авылдашым Зәбир дустыма

Агымсуга карап гыйбрәт алам —
Карашларың сулар көчендә.
Синең акланыңда печән чабам,
Чабам, Зәбир, синең өчен дә.

Агачларга карап гыйбрәт алам —
Яктырасың яфрак эчендә.
Синең акланыңда җиләк кабам,
Кабам, Зәбир, синең өчен дә.

Сабыеңа карап гыйбрәт алам —
Улың бигрәк синең төсеңдә.
Очратам да, сөям яшькә тыгылып,
Сөям, Зәбир, синең өчен дә...

*1985*

## Төнге авыл

Капка төбе. Мин ялгызым.
Янымдагы таш бүкән
Айдан күз алып яктырган; таш бүкән күзле икән.
Ата-инә, яр юк, һичкем таш кочмаган, үпмәгән.
Көн буе үпкән кояштан суынып та бетмәгән.
Чемченеп күк хәтфәсендә йөзә ай — алтын бәрән;
Шушы айны үз итмәсә, һәр адәм гомере әрәм.
Утырам нурлы сын булып, иңдә төннең яртысы.
Шылт итми адәм вә яфрак, читән вә каралтысы.
Утырам карап авылның, үтеп кыл карасыннан,
Кичен түшәккә авуын чыбылдык арасында.
Тере дә, үле дә түгел, кем исән — мырлап беткән;
Кичә кичергән афәттән гүя ул мәрткә киткән.
Ишек биксез, бакча чиксез, мунчасы тәрәзендә
Ай йоклый... йоклый бал корты

башлаган кәрәзендә.
Коела күктән шым гына аҗаган балкышлары.
Башлана башлый башаклар тс-тсы, чыш-пышлары.
Кайдадыр авыл очында үкседе, тынды көчек.
Эче авыртты, күрәсең, ачыган катык эчеп.
Янә тын... Иллә дә рәхәт!.. Кинәт бер каз елгада
Каңгылдый, авазы төнгә хәнҗәр булып кадала.
Кит, гауга! Кит миннән, көрәш!
Бир, Ходай, миңа тынлык!
Тынлыкны мактыйм үземдә көчәйгән саен коллык.
Күкрәгемдә кузгалган көч «мин разый»га авышып
Торганда, ишетәм арбаның шыгырдаган тавышын.
Ыңгырашып, якыная йөк; аты айлы караңгы;
Кайта бүрәнәдән кемдер — төнге урман карагы.
Кагылып үтә җил — борынга усак ачысы үрли.
Таш күрә мине, тик менә ут күршем генә күрми.
Борылып айлы тыкрыкка, калтайган арбасыннан
Ул бүрәнә гөрселдәтә кычыткан арасына...
Күрешәсем килеп китә, яшәгәч гомер кичеп.
Ат тугарыла.Ябыла мәгарә сыман ишек.
...Утырам капка төбендә, иңдә төннең яртысы.
Шылт итми адәм вә яфрак, читән вә каралтысы.

*1990*

## Татар китабы

*Әбрар Кәримуллинга*

Кара төннән чыккан кояшымдай,
Ташта чәчәк аткан гөлемдәй,
«Кем мин?» диеп типкән йөрәгемдәй,
Телле телсез булган телемдәй,
Казна түгел, халык көче белән
Гасырлардан ямьләп ил таңын,
Йөзем, телем һәм күземне ачтың,
Татар китабы, әй, татар китабы!

Табигатьтән мирас зиһенемдәй,
Киләчәккә илткән юлымдай,
Дуслар кулын кыскан кулларымдай,
Саф һавага мохтаҗ тынымдай,
Мәңге адаштырмас маягымдай,
Сине, язмышымның уртагын,
Тузан да төшерми саклап киләм,
Татар китабы, әй, татар китабы!..

*1985*

## Татарлар, берләшегез!*

*(Җыр)*

Җавап тотар заман килде —
Байракка тиңләшегез.
Иман нуры булып тамсын
Коръәнгә күз яшебез.
Азатлык өчен җанны да
Кызганмый көрәшегез.
Таңнарда серләшегез —
Татарлар, берләшегез!

Арабыздагы имансыз
Карагруһ көяләрен,
Милләтен сатып мал җыйган
Бар эшем ияләрен,
Тамырлары белән йолкып,
Кояшка күрсәтегез.
Бер телдә сөйләшегез —
Татарлар, берләшегез!

Без — илен сөйгән илдәшләр,
Егәрле, сәләтлеләр,
Ватаннан ватансызлыкны
Куарга сәбәплеләр.

Кайтып туган нигезләргә
Ил өчен көрәшегез!
Бер моңда гөрләшегез —
Татарлар, берләшегез!

*1991*

*** * ***

Адаштым таныш урында, нык аек булсаң кыен;
Упкыннарга алып керде кемнәрдер таккан уем.

Тауга тезләнгән авыллар тауга ни ялваралар?
Кысыр болытлар «Бетмибез!» дип микән кабаралар?

Тирбәлә телдә якты сүз, тик нигә өзеп булмый?
Ник җиргә шатланып баксаң, кайгырмый түзеп булмый?

Сине уйласам, и тормыш, җаным җырлар яргыта;
Тик халкыма сузган чакта, кемнәрдер кулдан тота.

Маңгаемнан нур чәчелә — томанда нурлар фидан;
Намусның тук базарында сатылып бетте иман.

Күктәге барча мәҗүси аллалар мине сөйми.
Бу хакта пртакул белә, кеше дә шулай сөйли.

Томан сукырайткан кояш күрми батышка күчә.
Ул да, иртән яктырам дип, кичен упкынга төшә.

*1986*

## Вулкан төбендә, тетрәнеп...

Тышкы һәм эчке матурлык
Һич кенә төгәл килми.
Даһилар чибәр булмыйлар,
Чибәрләр шуны белми.

Вулкан төбендә тетрәнеп
Яратылганда даһи,
Табигать җан белән тәнне
Адаштыра, билләһи.

Ярала ялгыштан дөрес,
Бәхеттән — бәхетсезлек.
Җанда — илаһи рух, тәндә —
Мәһабәт килбәтсезлек.

Чибәрләрнең даһилыгын,

Даһилар чибәрлеген
Үлчи бер нәрсә: сөюнең
Трагик төгәллеге.

*1986*

*** * ***

Казыймын кызгылт томаннар,
Казыгандай кызыл комны.
Нур катламына җитәрәк
Көрәгем шартлап сынды.

Ялгызым моңсу. Рәхәт тә.
Көчләми моңсыз төркем.
Сине матурлыйбыз диеп,
Пычрата алмый һичкем.

Упкын кырына шәм итеп
Элдем дә йөрәгемне,
Тырнаклар белән тазартам
Мәтесен көрәгемнең...

*1987*

## Трибунадагы телсез

Бәхетсез ил, әй, бәхетсез халык!
Шуып күкнең юеш түшеннән,
Күкрәкләргә кунган йолдызың да
Адәм күз яшендә шешенгән.

Алкышлардан туган ялгышлардан
Догасын онытып, тулган ай
Оеп йоклый... Улларыңа охшап,
Аең да кол — шул ук крепостной.

Үзгәрергә иде, әмма шартлар
Бик тиз үзгәрмәслек үзгәрткән.
Күтәрергә иде халык күзен
Тирес көри торган көрәктән.

Бөекләрдән көек исе килә...
Өченче мең кергән заманда
Әле һаман мәетләр яндыра
Сталиннан калган команда.

Бәхетсез ил, әй, бәхетсез халык!
Түгел идең болай ваемсыз.
Кичә трибунада телсез калдың,
Бүген — утсыз, сусыз, каенсыз...

Уян, илем, уянмасаң — үлем!
Без сине үлемсез яраттык.
Синең хакка кан тамырларында
Кызыл кан тупларын шартлаттык...

*1988*

## Энҗе турында баллада

Тагын давыл купты... Бу давылда
Яңа энҗе, диләр, ярала.

Энҗе эзләп дулкыннарга чумам,
Энҗе нуры кирәк ярама.

Диңгез төбен кармап, кулга нидер
Эләктердем... Нурдай тишелеп,
Ярга чыксам — аһ! — энҗе дигәнем
Баш сөяге икән кешенең!..

Утка пешкән сыман, башны кире
Орам дигән мәлдә упкынга,
Мине, мәгънә колын, тиргә салып,
Өн тетрәнде:
— Адәм, мин монда!
Саф сөю һәм ирек өчен, — ди бу, —
Көрәштем — алдандым — ил күрде:
Кара яшьтән йөрәк ялкынында
Кайнап, ак энҗеләр өлгерде...
Башкисәрләр башымны кисмәде.
Мактап яшәттеләр... Сагыздай
Яшемә — сизмәдем — кайчан, кемнәр
Төс үзгәрткеч агу тамызды?

...Мин шикләнеп күз сирпим.
Гүяки
Нур өермәсендә кояшның
Йодрык кадәр ике энҗе яна
Күз чокырларында бу башның...
Кем булган ул? Гыйсъянчы?
Ил сатып
Даһилык яулаган шайтанмы?
Инде илгә, мин чын энҗе диеп,
Сәнгать сыйфатында кайтамы?

...Диңгез, илһамланып, тау актара,
Айкылычлар уйный ялтырап.
Энҗе тулы баш сөяге белән
Нишләргә дип аптырап,
Ярда торам...

*1987*

## Халык Бабасының теле

*(Эстон шагыйре Матс Трааттан)*

Менә кабер. Юк баш очында таш —
Борынгы Тел монда җирләнгән.
Онытылган кабер... Аңа хәзер
Килеп баш та ия белмиләр.

Ә Тел тере. Кабереннән казып
Алырлар дип яши һаман да.
Тагы көнгә чыгар сымак
Гүзәл
Ия, хәбәр, затлар, заманнар...
Иреккә чыкканчы һәм кабаттан
Әйләнгәнче уртак бәхеткә,
Таш һәм тузан белән серләшә ул
Җир астында — тирән ләхеттә.

*1987*

## Нурлылар җыры*

*Уфада «Нур» театры ачылу уңаеннан*

*(Җыр)*

Яктыртты «Нур» Уфабызны! Нурга тулды юлыбыз!
Сез дә нурлы, без дә нурлы — һәммәбез дә нурлыбыз!

Сүндерсәләр дә сүнмәдең, кабындың, «Нур», яңадан.
Яралгансың туган телдән — мәгърифәтле анадан.

Уят син, «Нур», халкыбызның кызларын һәм улларын.
Чирттер күңел кылларында сихри татар моңнарын.

Яшә син, «Нур», нык тор син, «Нур»,
изге сәнгать сагында.
Иркәләп үстерер халкың кояшлы кочагында.

*1989*

## «Түгәрәк Имән» төбендә

*(Яңа гасыр «тентүен» үткәндә)*

Күрмәделәр мине, ай, күз белән,
Тик сөйлиләр шелтәле сүз белән.

*Халык җыры*

Батырша һаман юк. Күзне кисеп
Исә кызгылт сәмум ниндидер.
Җилкендердем, ил күндердем, дигәч,
Юк, йөрәк, яңадан җилкендер!..

Минме азатлык дип айкалмадым,
Бүген яңа гасыр тентүен
Үткән чакта
Сорыйм: милләтме без?
Әллә пошмас коллар көтүе?!

Бер тетрәнү көтә бездән тарих,
Бер кыйралыш көтә Илаһи.
Ялган Ватан өчен корбан — савап,
Үзебез өчен гөнаһ микәнни?

Ишетәсезме: күкләр күкри! Күкри!
Күрәсезме: ялт-йолт яшеннәр?
Безнең богауларны, дөбердәтеп,
Офыкка бушата яшь өннәр?

Мин үзем шул яшеннәрдән туып,
Баш күтәреп хурлык-коллыкка,
Ак болытларымнан чалма киеп,
Җиргә сибәм якты орлыклар.
Үсегез, үс, ирек пәрвәрләре!
Чүпләр үстермәгез арага.
Егерме беренче гасырга кол керү
Гөнаһ татар дигән карьяга*!
Ишетәсезме: офыклар дөберди?
Күрәсезме: яшен кайрала?
Татар кылычының ак йөзендә
Алсу шәфәкъ булып кар яна!..

*1999*

## Кеше эзләп киләм...

— Мин иреклe! — диеп кычкырттылар.
Сайлау җитсә, иңнән сөйделәр.
— Сөйлә! — диеп, үз каным сугарган
Байрак белән авызым төйделәр.

Бик тә сөйләр идем — тел әйләнми.
Байрак аны таштай бастырган.
Тел үзенең һәрбер пәйгамбәрен
Байракларга төреп астырган.

Пәйгамбәрсез, аннан кешесез калгач,
Юлбашчыларга тик юлыктык.
Без, «шагыйрьләр», тарихта — тәү тапкыр —
Халыкның аһ-зарын оныттык.

Бер кулыма — кан сауган исемлек,
Бер кулыма шәмдәл-ут алып,
Көпә-көндез кеше эзләп киләм,
Кеше диңгезендә буталып.

Күз бәйләнде, ә кала караңгы,
Ул киловатт санап кысыла.
Урамнарны төнге микроскоптан
Мин карыймын салып учыма...

*1988*

## Ике елга тамагында

*В-га*

Синең белән авырлык күрмәдек —
Тик сөю газабын кичердек.
Сусаган атларны кичүләрдә
Шәфәкъ дәрьясыннан эчердек.

Әле ике елга тамагында,
Агачлыкта, шаулы агымның
Куркыныч төшендә, кочаклыйсым
Килде сине —
Ярты җанымны...

Яшьнәде күк!.. Изде безне шәүлә:
Агач дисәм — котсыз колгалар!
Яфрак итеп акылын койган колга —
Бу кайсыгыз эше, елгалар?!

Нәрсә янап гыжный бу зәкъкумнар*?
Тарата шом, чыш-пыш, шыр ялган?
Агуыннан череп, авар тиздән —
Минем моңнарымнан болганган.

Кырлы курай сыман утырып корып,
Мәскәүдән җил чакырып котырган —
Дога кылам: елга аеры акмас
Черек кәүсә салган коткыдан.

Дулкынланам, гүя беренче кат
Сине күрергә дип килүем.
Мине мәңге дулкынлансын өчен
Син вакыйга иттең сөюне.
Сине үбәм... Зәкъкум артларыннан

Күзәтәләр — беләм, килешми.
Шартлатыр да идем — бу дөньяга
Минем дулкынлану җитешми...

...Төн бик якын. Җәллад өйгә кайтып,
Минем кулъязмамны актара.
Ә без ике елга тамагында
Шәфәкъ эчерәбез атларга...

*1989*

## Ут

Без өшедек. Аһ, хәерсез сәгать!
Туңып үләбезме далада?
Буран аша ай кыйшая — шадра! —
Гүя аны пәри ялаган.

Җылыталмыйм сине... Соң, үземне
Учак итим мәллә, сөйгәнем?
Синең өчен ят балдактан үтеп,
Утка ике гомер түләдем...

— Йокым килә... Йоклат әкият сөйләп! —
Дидең дә куркыныч карадың.
Бу дәһшәттән, килер бәла тоеп,
Чигә чәчем кардай агарды...

Ә давыл котырды... Ашык-пошык
Корыштырган киндер куышның
Бердәнбер казыгын какшатып, җил
Үпкәдән үкчәгә шуышты...

Кайдан бу гамь? Көтмәгәндә җиргә,
Гүя утка сузып кулымны:
— Бу ут! — дидем. — Кер учакка тизрәк!
Безнең ут бу... Бу ут — борынгы!

Кар сарылган якты сының белән
Бербөтен боз булып ул чакта
Иелдең син ышаныр-ышанмас
Мин бар иткән сихри учакка...

Кем күз буды? Караштан ни туды?
Күрүемчә, канлы кызарып,
Арабызда учак яна иде —
Җирдә исән калган кислород.
Белгән догам укып, ут өстендә
Бармакларын удым кулыңның.
Эреде керфегең... Күзең... Үзең...
Һәм елмайдың: «Менә җылындым!»

Без шат идек. Хыялый учакка
Яккач соңгы өмет чималын,
Ниһаять, уянды җанда ач рух —
Ходай Тәгаләсе Иманның...

...Дөнья тынды. Ай, актарып чыгып
Пәриләр өерен давылның,
Моңсу төнге күктән карап йөрде
Биләмәсен йөз мең авылның...

*1990*

## Укучыма үзем турында

Сиңа дигән йөкне киң җиһанга
Алып чыгам дисәм, ни баса?
Мин — ракета, таш баганаларга
Арканланган хәлдә ләбаса.

Двигатель эшли, ягулык мул,
Юк йөгемдә хәтәр кораллар.
Омтылам — күз чәчрәп чыгар! — аркан
Өзелми, җитмеш кат уралган.

Сакчылар күп: үзәктән көч алып,
«Әле бай», «Бик Бай»ларны күтәргән
Колбиләүче әдип ул — россиян! —
Мине җырдан читкә этәрә...

Алар миңа махсус тәмуг ясап,
Утын ташыганда учакка,
Мин кузгаткан намазлыкларыннан
Иблисләре тулды кочакка.

Үкенмимен, әгәр каләм тәмләп,
Йолдызларга иркен үрелсәм,
Шигъри кроликлар арасында
Чәнечкеле гыйфрит күренсәм...

Укучы дус, әйдә, кылансыннар.
Килер заман аерып алардан,
Иске йортның ишеген ачкан сыман,
Ачар әле мине яңадан.
Рухның дәһри колбиләүчеләре
Чыбыркыдай череп сүтелер,
Шигърият иркәмнән тел, нәсел, җир —
Ил алдында гафу үтенер...

Укучы дус, сиңа еллар аша
Килми калмас моңсу бер хәбәр.
Үзем үлсәм — Җәбраил, диярсең,
Үтерсәләр, әйт, ул — Пәйгамбәр.

*1990*

## Язгы нурлар

*Флүрә Низамигә*

Ачылган кораллар сыман,
Агымсу asларыннан
Җемелди энҗе күрәннең
Былтыргы карасында.

Кабынгач урманда язның
Нурлы борылышлары,
Иркенәйде күрәннәрдә
Энҗе тын алышлары.

Кыйналып чатнама кышның
Ирексез камчысында,
Әверелә агымсуга

Ярату тамчысында.

Кояшның бер генә бөртек
Йөземен кабып карап,
Зеңгелди хәрәкәттә кар —
Энҗе төялгән кораб.

Эленә дугага боҗра,
Чарлый төн тамакларын —
Гөпелдәп төшә карларның
Ап-ак аргамаклары.

Күр, әнә һәрбер чокыр яшь,
Зәңгәр нур уйный-күлә,
Кар бөртекләре кешедән
Хислерәк була белә...

...Хәят тамыры — акылдыр.
Ул акыл хистән икән:
Урман кар базында тойдым —
Мин әле исән икән.

*1991*

## Без исән!*

*(Җыр)*

Ташлар басты, ташлар басты безне,
Биш гасыр ташлардан изелсәң,
Таш күзеннән җандай чәчрәп чыгып,
Әйтү ләззәт икән:
«Без исән!»
Җимертелгән шәһре Казан сыман
Атылырга рәткә тезелсәң,
Җәһәннәмнән кабат күтәрелеп,
Әйтү ләззәт икән:
«Без исән!»

Безне талап, алар баемады,
Хәер сорашалар — син күрсәң!
Без һаман бай, чөнки таңнан торып,
Милләтебез эшли.
«Без исән,
Без исән!
Без исән!»

*1992*

## Егъла, татар!

*Атаклы тарихчы-археолог*
*Равил әфәнде Фәхретдингә*

Болакның балак буйларын аркылы-буйга гизеп,
Штиблет белән бер күзле миллион микробын изеп,

Мин килдем Сезгә, и бәнем, күз яшем камчысында,
Калмаган иде милләткә өметнең тамчысы да;

Әмма, кем!.. Синең гаиләң, нурланып, ачты ишек.
Куандым күреп — Ярабби!.. — түшәмгә аскан бишек.

«Чын ир, — дим эчтән. — Кыйналып,
җитеп шушы яшенә,

Бәби үстерә... Түгел без бәлҗерәгән кәлҗемә!..»

«— Булат бу, — дидең. — Оныгым.
Көндез — көр, төнлә — җылак.
Җитмәсә, черки — бимаза. Якында — Кабан, Болак».

Хушландырып ач тамакны, күрсәткәч ятар урын,
Бәлҗерәгән кәлҗемәдәй без китеп бардык кырын.

Изрәп, үлеп йоклаганмын — черки бар ни, булса ни;
Уянам — чү! — күгәрчендәй гөргелдәп егълый сабый!..

Ул егълый, килен борчыла, мин — шат, горур, гасаби;
Милләт бар һәм булачак, — дим, —
егъласа хет бер сабый!..

Егъла, туксан өч сабые! Егъламас — көнен күрмәс.
Яңа гасырга бу татар инде кол булып кермәс.

Егъла, татар, Сөембикә, Кол Шәриф рухын чакыр!
Бишектән бугаз чарласаң, синнән, шәт,
чыгар шагыйрь!..

Төнге өчтә, егълап, Казан болакларын* яңраткан
Бер Булатның чеңрәвенә мин, милләт, сөенеп ятам...

*1993*

## Балалар бакчасы

*Рәшит Әхмәтҗановка*

Бар Казанда бер йорт... Шагыйрь дигән
Куркыныч ләззәтле ат алып, —
Монда
Мин һәр төндә ята идем,
Баш астына салып балтаны...

Хәтерлимсең, тәкъсир: көндез монда
Уйнап-көлсә гамьсез сабыйлар,
Төндә Суконканың бандитлары
Налет ясап, йортны талыйлар
Иде...

Ә бит миңа, ялгыз каравылчыга,
Кол Шәрифтән калган бер нәзер:
Дошман килсә, балтаң чәчкә атсын,
Гүяки кып-кызыл канәфер.

Гомер бакый күктә җырны саклап,
Рәхмәт ишетмәскә өйрәнгән
Ай төшә дә, алтын калкан булып,
Мине каплап ята келәмгә...

Сабыйлар кызганыч... Бакчабызда
Алар әле югын юклар да,
Йөрәк әрни... Канәфер каны да
Түгелмәсен уенчыкларга...
Келәмемә төреп, аемны да
Урлап ашарлар дип,
Ничек тә —

Балтадан да үткер как гәүдәмне
Кадаклап, күз йоммыйм ишектә...

Балта йөзе, аннан чәчелгән нур
Һаман да шул хокук көчендә,
Чөнки аны мин үткерли идем,
Рәшит дускай, синең өчен дә...

*1992*

## Хәсән Туфанга

И минем сәждәм шагыйре,
Ниһаять, теге Вакыт
Ватылды...
Яңа Вакыттан
Камчылый безне тәнкыйть.

Тыйнак идең... Тар тәүфыйкның
Сәбәбе кемдәлеген
Белгәч, тыйнаксыз булмыйм дип,
Тәмуглар көндәлеген
Хәтта Син язмадың, абзый,
Тыйнак диссидентыбыз:
Чал чәч учмасы — кылган баш,
Буби, Идел-йортыбыз...

Туфанча сүтеп шигырьнең
Иҗеген, өтерләрен,
Юнәлтмәдең Нероннарга
Һөҗүм компьютерларын.

Калдырган булсаң безләргә
Каземат вәгазен дә,
БМОга таратыр идек
Фифарус кәгазендә.

Куркак тыйнаклыкта бөлдек.
Шуңа, йотып яшьләрен,
Һич мантый алмый «мөстәкыйль»
Татар энекәшләрең.
Ямап аклы күлмәкләрне,
Бераз күз йомып кисәк,
Без һаман кер күтәрәбез,
Без хәтта һаман исән.

Ясыйлар синнән фәрештә,
Пәйгамбәр идең бугай...
Сиңа чәнечкеле кырда
Фатиха биргән Ходай.

*1992*

## Суфиян бабай бәете

Укыгыз бәнем яуда язган сүзебезне,
Күргән кебек булырсыңыз үзебезне.
Менгән атым җирән түгел, шомырт кара,
Яурынында мылтык-кылыч ялтырап бара.

Килеп җиттек Донец дигән су буена,

Гаҗизләндем сугышның нык булуына.
Дошманнарның туплары бик ерак ала,
Ерак ала, төшкән җирдә чокыр кала.

Сулар акты, судан да күп каннар акты,
Чигенмәдек, дошман үзе безгә капты.
Менгән атым башын чайкый каршы җилдә,
Кайтыр көнем булыр микән туган илгә?

Сайрый былбыл, сыкрый аккош бу җирләрдә,
Җөмлә агач яфрак яра тугайларда.
Кайтыр көнем булса икән туган илгә,
Хәсрәтләрем барчасы да бетәр имди.

Үз хәлемне, күргәнемне бән сөйләдем,
«Йосыф китабы» көенә бән көйләдем...

*1992*

## Сагыш

*(Алтмыш яшем уңаеннан)*

Мин сизәм, шуңа да сызам,
Сызып түзәм әлегә, —
Әдәби кичә Кырлайдан
Күченә Кәркәлегә.

Болай да сагышлы идем,
Сагышым тагын артты —
Әдәбияне ничегрәк
Каршылар яше-карты?

Табылырмы аек инсан,
Инсафлы күренерме?
Әллә имансыз чокырга
Лап итеп сөрлегерме?

Егъламасмы урамнарда,
Очратмый бала-чага?
Мәптектә Тукайны тапмый,
Күчмәсме урысчага?

Әдәбиянең күчәре —
Әдәбият кичәсе.
Ун гасырны исән кичеп,
Монсын ничек кичәсе?

Әдәбиясен култыклап
Килмәсә Әдәбият,
Өязе тугайларында
Йөземә калкыр оят.

*1999*

## Азнакайдан үтеп барышлый

Шәһәр утларының җылысы юк.
Керфексез күз — шәһәр тәрзәсе.
Балкондагы азык әрҗәсендә
Кымшана ач йолдыз гәүдәсе.

Ун көн элек эленгән ап-ак кер,

Әнә җепшеп янә кипшенә.
Туктап, шул керләрне кертеп китсәм,
Аңлашылыр микән кешегә?

Чакматаш юллардан үтеп барам...
Эх, вакыт юк кереп йөрергә!
Менә шулай, халыкка кермичә
Үтеп китте безнең гомерләр...

Сорау туа, шомарган юлларда
Очрап куйса җансыз сикәлтә:
«Бу йортларда синдәй кеше яши,
Бар, бел — үзең бүген ни хәлдә?»

Үксим — моңа кадәр ир-егеткә
Ник бирмәдем үгет? Ә нигә
Сузмадым чәчкәләр чын гүзәлгә?
Татлы ширбәт — һәрбер нәнигә?

Экраннардан пышылдыйсым килә:
Ник мондый без? Нигә дәшмибез?
Ник бу кадәр дөрес уйлыйбыз без?
Ник бу кадәр ялгыш яшибез?

*1996*

## Автобуста

Үземнән алдагы рәттә
Яшь ана, чиста гүзәл,
Сабыен уйнатып килә, —
Мин, гашыйк, көчкә түзәм.

Ул аны чут-чут үпкәндә,
Җилләре миңа тия.
Кырык корама юрганда
Мин ятмыйм икән нигә?

Нигә хет бер уенчыгын
Ул миңа бирми икән?
Нигә ул мине яңадан
Биләүгә төрми икән?

...Эндәшми күзәтәм аны
Утыргыч арасыннан.
Кушучлап мәхәббәт җыям
Күзләре карасыннан.

*1997*

## Кабанда давыл

*(Романс)*

Тыйнак булдым — ихтыярсыз калдым,
Кадерләдем — калдым кадерсез.
Күренми шәһәр, күренми авыл.
Казанда тыныч, Кабанда давыл.
Үзгәртергә мине әзерсез дә,
Яшәтерсез микән җәберсез?
Күренми шәһәр, күренми авыл.
Казанда тыныч, Кабанда давыл.
Башларың әйләнсә көймәдә,

Адашасың икән күлдә дә.
Күренми шәһәр, күренми авыл.
Казанда тыныч, Кабанда давыл.

*1997*

## Шагыйрь Кәрам Бакиров

Такташтай, сварка сыман,
Зәңгәр күз янып тора.
Бик яхшы шагыйрь булса да,
Гел читтә калып тора.

Ул икенче инфарктан
Чак-чак котылып килә.
Коммунистик урамнардан
Бауга тотынып килә...

*1979*

*** * ***

*А-га*

Сине эзлим. Беләм, якындасың.
Адаштыра безне кемнәрдер.
Нәрсә ашый күзне? Ач төтенме?
Бәлки, илдән качкан көлләрдер?

Аерылу — ят, кавышу — җинаять.
Күзләреңнең шомырт карасын
Якты чыктай яшькә манам, әйдә,
Җем-җем итеп, чем-чем карайсын.

Без бәйләнгән теге бердәнбер җеп
Корыч арканнан, дим, түземдер.
Кавышулар мөмкин... булмагандай,
Аерылу да мөмкин... түгелдер.

Их, белсәмче!.. Беләме соң яшьлек
Чишмәсен кайсы тау култыклар?
Шулай гомер үтәр, бер зиратта,
Сәйдәш нотасыдай, юл туктар.

Исемемнең варисәсе бар ла,
Җисемемнең юк шул варисы.
Варисымны тәмуг төбеннән дә
Килә, дускай, эзләп карыйсым...

*1993*

## Заман башында

*В-га*

Дөнья тыныч. Туплар атмый. Әмма
Нидер, кемдер шартлый... Беләсең.
Шундый тыныч... Җәлил Әминәсе
Булып күз алдыма киләсең.

Сиңа төртеп күрсәтәләр сыман:
«Халык дошманының хатыны».
Төш кенә бу... Бу — дәүләтле булган
Кыргый курчак уены, алтыным...

Каурый белән хәят көзгесеннән
Бар тапларны сөртсәм, кыз бала,
Гүзәл Илаһ булып бу көзгедә
Синең генә нурлы йөз кала...

Карашыңның кырыс сөрмәсендә
Кайдан мондый моңсу тирәнлек?
Яшьли сиздем: милләт милке икән
Синең түзем, синең зирәклек.

Соңламаска! Кояш күкрәгеннән
Сыдырып бераз сөю сөрмәсен
Илгә бирик! Кеше «сөймичә дә
Яшим» дип алдана күрмәсен.

Кем өчендер заман ахыры бу,
Безнең өчен башы заманның.
Заман башы сөюе хакына
Пычак йөзе сыман таландык.
Сак бул, дисең. Әйе, мәкер сансыз.
Тыныч туплар алдан атмыйлар.
Буровойда җиңел тимер — тонна,
Фәрештәләр мине саклыйлар.

...Төнгә каршы дошманга гөл бирик.
Ул гөл сөя, чөнки үлемсез.
Һәм, ут алып, тауга күтәрелик,
Дусларга ерактан күренсен.

*1989*

## Бөреләр

Сүгенә күрмәгез инде,
Сандугач килде кичә.
Һәлакәт сыман яңарып,
Яфрак җилләре исә.
Гаепсезгә таламагыз —
Җан туза, гомер уза.
Бөреләр, шартлап ачылып,
Ерактан кулын суза.

Күрсәтмәдән читкә чыгып,
Сез, сабый бөреләрем,
Мине күреп вакланмагыз,
Калыгыз эреләнеп,
Булырсыз тереләрем.

Агач анасы көндезен
Бөреләрен уйната.
Бер-бер хәл булса дип, төнлә
Киендереп йоклата.

Миңа тик кул сузган өчен
Көннең шундый чагында
Тамырдан куптарылсагыз
Бульдозер кочагында,
Нишләрсез ул чагында?

Сезне яклап җаһилләргә
Каршы атлармын кебек.
Тимер чылбырлар астына
Ятып шартлармын кебек.

*1989*

## Кырым. Таң ата. Беренче күрешү

Уянам да... Зәңгәр, зәңгәр!
Таумы шулай, әллә таңмы?
Сикереп торам һәм җылыймын, —
Алда — диңгез, артта — пальма...

Поезд килә оетып кына,
Оетып кына ал таң ата...
Агач уяу: анда төнен
Ишек каккан тавыш ята.

Болыт бушак, галәм кысыр,
Диңгез ятим, хуҗасыз яр.
Хуҗасыз яр — нужасы бар,
Бу нужаның узасы бар...

Таңга нәрсә? Кысрыклый да,
Болыттан буш сал агыза.
Чәчкәләрнең авызын ябып,
Алдаткыч балын тамыза...

...Кара диңгез оеп кына
Кичәге чүп-чарны көри.
Кәрзин аскан урыс карты
Ярдан шешә җыеп йөри...

*1983*

## Диңгез ярында кызына

*Василий Беловка*

Урыс баскан Кырым
Төягән дә кырын,
Бөтен җирне биләп,
Ярда ята кырын.

Чәче иңгә яткан,
Сакал-мыек баскан.
Кендегенә кадәр
Алтын тәре аскан.

Дин күкрәктә түгел,
Дин йөрәктә була.
Дин йөрәктә булса,
Бик кирәк тә була.

Урыс фаҗигасе
Динсезлектә генә.
Мәҗүси мин-минлек
Мәнсезлектә генә.

Урыс фаҗигасе

Азгынлыкта гына.
Ялган тарихына
Җитми нокта гына.

Мин Кырымны бүген
Кулларыма алдым.
Сабынлап, диңгезнең
Күбегенә салдым.

Укшыттым, җепшеттем,
Кырындырдым гына!
Кыргычлап, сабынлап
Юындырдым гына!..

Ни күрәм? Диңгездән
Чыга чиста сабый!
Аны хәтта дөнья
Кеше итеп таный!

Йомшак сөлге белән
Кипшендердем генә!
Тәресенә ымлап,
Төшендердем генә:

Динле бул, илле бул,
Басып кына алма!
Башка милләтләрне
Кайгыларга салма!

Баскан җирләреңнән
Чыга бел син салмак.
Чыгалмасаң салмак,
Үзең җирсез калмак!

Әгәр тыңламасаң,
Миннән җавап алмак.
Шул хакта кисәтеп
Яныйм, энем, бармак...

*1996*

## Кырым

Җәйрәп ята күкерт-зәңгәр
Кара диңгез.
Дулкын сигез, диңгез тигез —
Безнең нигез
Сезне яшәртергә.
Илдә яшәтергә.
Дулкын тугыз булса, диңгез
Какшый төптән.
Кулым саптым, энҗе таптым —
Гомере үткән
Көтеп сезләрне.
Кара күзләрне.
Тозлы дала, яшел үзән,
Очлы таулар.
Очтан очка, очтан очка
Суздым баулар
Яшьне киптерергә.
Йөзем иктерергә,

Сезгә җиткерергә.

*1986*

## Айлы манара турында баллада

*(Симферополь базарында*
*хәер сорашкан урысларны күргәч)*

*Дустым Бәкер Нематуллаевка*

Бер мәчетсез калган Акмәчеттә,
Алтмышлап елдан соң урамда
Бер айлы манара нигезен эзли,
Аh, манара — даhи дивана!
Илдән сөрдерсәләр — җилгә кер!
Җилдә илгә кайттың, әй, Бәкер!

Кичәге талаучы юл сорамый,
Хәер сорый. Бирмә син аңа.
«Алсын! — ди манара. — Иман калсын!»
Аh, манара — даhи дивана!
Көрәш иманга тиң — бермә-бер.
Иман белән тере син, Бәкер.

Акмәчеттә тукталыр җир тапмый,
Сусыз таш далада күр әнә
Галәмгә ук булып күтәрелде,
Аh, манара — даhи дивана!
Аптырама, Бәкер, күп мәкер.
Аерым чыккан җиргә бергә кер!

Акмәчеткә елышып, йорт бетерден,
Дүрт тарафтан ундүрт эт өрде.
Гаиләңә манара, яшерми,
Су, ут, нан hәм иман китерде.
Син, караңгы төшкәч, өйгә кер.
Нинди яхшы кеше син, Бәкер.

*1996*

## Казан — Бакчасарай — Истанбул*

*(Җыр)*

Кайсы яктан, кайсы тарафлардан
гөлбакчалар хуш ис бөркиләр?
Хуш ис бөркиләр.
Алтайлардан Әдрән диңгезгәчә
җир тетрәтеп үтә төркиләр.

Кушымта:

Казан–Бакчасарай–Истанбул.
И-и-и,
Истә булмый диме, истә ул.

Алтайлардан Әдрән диңгезгәчә
җир тетрәтеп үтә төркиләр.
Үтә төркиләр.
Җәйләүләрне бергә җәйлик диеп,
төркиләрем куллар селкиләр.

Кушымта.

Кул селки төркиләр тарихлардан,
күрешик дип уртак нигездә.
Мин бүгеннән юлга чыгар идем,
басылганмы давыл диңгездә?

Кушымта.

*1996*

## Дудай маршы

Ир, дибез без, ир, дигәндә күкрибез: ул син — Җәүһәр!
Җир, дибез без, җир, дигәндә тетрибез: ул син — Җәүһәр!

Ук, дибез без, ук, дигәндә күрәбез: ул син — Җәүһәр!
Ут, дибез без, ут, дигәндә беләбез: ул син — Җәүһәр!

Таш син безнең, яшь син безнең, син һава безнең, Җәүһәр!
Баш син безнең, аш син безнең, син дәва безнең, Җәүһәр!

Син — үлемсез, синең кебек Җәүһәрләр мәңге үлми.
Синең рухың ирек даулап чакыра, гүргә керми.

Безнең терәк, син — куш йөрәк — Алладан килгән бүләк.
Җимерелсен империя — шул безнең изге теләк.

*1996*

## Телсез «Әтен» турында баллада

**1**

Сабый баланы кыйныйлар.
Ул, телсез, эзләп рәтен,
Аңлатмак була, мескенкәй:
— Әтен-әтен-теннәтен!..
Әтен-әтен-теннәтен!..

Исеме аның Ринат ла,
Тик гавам, тотып шартын,
Исеме белән зурламый,
Хурлый дип «Әтен-әтен».

**2**

Үзе кебек кәләш табып,
Бастылар яшьлек дәртен.
Никахына шаһит кылды:
— Әтен-әтен-теннәтен!..
Әтен-әтен-теннәтен!..

**3**

Кичә без янә күрештек —
Кырыкка җиткән Әтен.
Ул елый мине кочаклап:
— Әтен-әтен-теннәтен!..
Әтен-әтен-теннәтен!..

Янында җиткән улы бар,
Егерме яшьтә, бәлки.
— Әткәй шәп, —ди ул. — Тик телсез,
Шунысы гына жәлке...

*2002*

## Сыерчык карлары яуганда

Карлар ява, сыерчык карлары,
Кайтыр кошларымны кабул ит.
Быел кышын күп борчу китердем
Син гафу ит, җаным, гафу ит...

Карлар ява, соңгы карлар ява,
Алар кышның кайнар яше бит!
Шатландырам, диеп рәнҗеттемме,
Син гафу ит, җаным, гафу ит...

Карлар ява, сыерчык карлары,
Алар ак розалар ише бит!
Пакьлек күреп, җан тәүбәгә килә,
Син гафу ит, җаным, гафу ит...

*1979*

*** * ***

Буразнада идем. Өн ишеттем.
— Мин — сөюең, сине эзлимен.
— Ышанмыймын, — дидем, — шушы сүзне
Әйтсәң хәтта алга тезләнеп.

Нәрсә күрәм! Тезләнде сөюем! —
Пар канатлы керсез фәрештә.
Үкенеч тә булган бу очрашу,
Фәрештәдән алган дәрес тә.

— Мин ямьсезмен.
— Син матурдан матур!
— Мин җансызмын.
— Җаның булырмын!
— Мин гөнаһлы.
— Үзем ярлыкармын!
— Миңа — тәмуг...
— Үзем керермен!

— Сөям! — диде сөю. Сынамакка
«Сөймимен!» дип әйтеп өлгердем.
Аһ, түбәнлек! Минем ак фәрештәм
Буразнадан торып йөгерде.

Кеше, нигә соң син кеше генә?
Ник канатсыз мин, дип тилмерәм.
Боз-ялкында сөюемне көтеп,
Мин тәмугта бүген җир сөрәм.

*1979*

## Песи баласы

Тирәкләрне аяу белми тарый
Сентябрьнең алтын аясы.
Яфрак аулый! — Гүя тычкан аулый
Метрикасыз песи баласы.

Алдана да... яшел күзләрендә
Чагылып китә яшькелт буранкай.
Йорт-җирең юк. Яшькелт бураннарда
Сөт бирсәләр, син эч, туганкай.

Өерелә яфрак... Сикерә ул!
Инде эләктердем дигәндә —
Оча яфрак... Шулай була кайчак
Хәтта наян песи белән дә.

*1979*

* * *

Очкын очты яшемнән —
Сөйдем шушы яшемдә.
Качып булмый мәхәббәттән,
Булмагандай яшеннән.

Мин киттем синнән, тыныч бул,
Йокымсыраган үзән.
Нәфрәтем белән бәхетсез,
Сөюем белән гүзәл.

Гади кеше түгел гашыйк,
Түгел ул катлаулы да —
Канатлы елмаюлары,
Канатлы атлавы да.

Күкрәктә таулар кузгала.
Сөюем итте һушсыз:
Үзем — ялкында, сүзләрем
Чыгалар аңлаешсыз...

*1980*

## Туган йорт тупсасында

Алсу иртә.
Кояш Кәркәлетауга
Алтын баржа сыман туктаган.
Сезгә кушуч алтын алып бирәм,
Үрелеп кенә туган тупсадан.

Чыклы салкын. Яланбаш. Яланөс.
Мин сабые һаман заманның.
Башта — кояш.
Билдән күләгәсе
Без төзеп бетмәгән сарайның...

Әти-әни!
Миңа ничә йөз яшь?
Тавыш-тын юк. Гомер үтүгә
Ышанмыймын!
Бары тал чажлатып
Җиңгәчәй мал куа көтүгә...

...Бала чакның сизгер ызаннары!
Якасында үлеп ачлыкның
Кеше бакчасыннан баш чыкмады —
«Кишер буры» дигән дан чыкты...

«Аһ, аминсыз!»
Ә ничек витаминсыз?!
Җәй кишердә үзәк ныгыттым.
Көзен исә ит кундырдым,
Шартлап

Ачылган чагында ногытның.
Шуның өчен монда, шушы төштә,
Каеш белән мине ярдылар,
Ярган саен мин елыштым җиргә,
Җырлар шунда яфрак ярдылар!..
Ярдылар да, суынсын бераз дип,
Салкын базга мине яптылар,
Зәңгәр күздән тамган зәңгәр яшьләр
Зәңгәр ташлар булып каттылар
Һәм мәңгегә шунда яттылар!..

Базда шайтан атланырга итте.
Мин аны акылга утырттым.
Кишер бирәм, дидем, алданмады,
Шигырь язам диеп куркыттым.

Туган җирем! Мин бер шат тамырың,
Син — тәүге кат күлмәк киюем.
Син ышанма иксән шагыйреңә,
Төче булса сиңа сөюе.

Рәхмәт, җирем, мине җырчың иттең,
Айкап киләм шигъри яланны.
Бушка мактап, алтын биреп түгел,
Кыйнап кеше иттең балаңны!..

...Көтү кайта. Тоташалар таулар,
Үзәннәрне алып култыкка.
Мал каршылый халык. Урам тузган.
Урам тузан белән тутыккан.

Төн куера...
Аҗаганнар уйный.
Игеннәрдә яшькелт шәүләсе.
Төн йокыда, өлгергән кыз сыман,
Буй җиткерә арыш гәүдәсе...

*1981*

## Яңгыр килә

Өреккән ат өередәй, кешни күк тарафлары,
Камчылап атларның ялын тарый ут тараклары.
Буталды дөнья!
Кайный ул яртылаш төсләр белән —
Зәңгәрне ашыйдыр кара, яшелне ашый көрән.
Сеңгәнбез илаһи моңга, табигать гамьнәренә,
Без дә адәм баласы да — эш телдә, тәндә генә...
Исте җил! Җилгәрде көннең әлсерәгән ялкавын.
Үзара шыбырдап, яфрак тапты тормыш ялгавын.
Тамды яфракка бер тамчы, тамды ике, тамды мең,
Югалды юк-бар аһылдау — калды кодрәт,
калды моң!

*1983*

## Нормандия–Неман

Бала чактан сиңа гашыйк булдым
Китабыңны тәү кат ачтым да, —
Чыланасым килә, Франция,
Койма яңгырларың астында.

Нормандия–Неман. Юлга төшкән томан.
Таралыр бу томан. Нормандия–Неман.

Сине сөюемнең чиге — сөю,
Телдән төшә — сыймый колачка.
Ут өстәек әле, Франция,
Яшәү дигән уртак кояшка.

Нормандия–Неман. Кош җим алмый кулдан.
Кулларга ни булган, Нормандия–Неман?

Әгәр сине күрми китеп барсам,
Мәхрүм итмә соңгы теләктән,
Илемә һәм сиңа, Франция,
Чәчәк атармын мин йөрәктән.

Нормандия–Неман. Исән безнең иман.
Таралыр бу томан, Нормандия–Неман.

*1983*

## Курортта очрашу

Яшелдән киенгәч дөнья,
Күпереп үскәч үлән,
Килдек без чит-ят якларга
Курортка хатын белән.

Күрәм, нәкъ пальмага охшап,
Бина күтәрмәсендә
Ак күлмәкле хатын тора
Неон өермәсендә.

Андый-мондый уй юк иде,
Тик күңел шайтан икән:
«Буе бар, — димен, — сыны бар,
Бу чибәр кайдан икән?»

Бер эзләп тапкан алтының
Кайда да алтын икән:
Янына килсәм, чибәрем
Үземнең хатын икән.

*1983*

## Язны көткәндә

Өязедә тал чүпрәсе әчи.
Кайры исе бәрә аръяктан.
Язны каршылыйм дип көрткә баттым
Ана казлар салган сукмактан.

Боз каушый да башламаган әле,
Тетрәнмәгән, язга узмаган.
Кызыл тәпи казлар бии бозда —
Томшыклары хәтта кызарган.

Минем чирем бик куркыныч түгел,
Ә шулай да шактый ярыйсы, —
Язның иң беренче тал бөресен
Килде минем чәйнәп карыйсым...

Чүпрә килсә, камыры килмәгән —

Ник күренми һаман бөреләр?
Былтыр киткән биләменнән кайтмый
Африкада мәллә йөриләр?

Ник ашыкмый әле быелгы яз?
Җаным сыкрый — нигә башланмый?
Ник бер бөре азат яз хакына
Кургаш ташуларга ташланмый?

Кил инде, яз!
Камыт бауларыңны
Шартлатып өз дә чык тәртәдән!
«Ниятең хак» диеп, чегән кызы
Әйтте кичә ике мәртәбә.

Кил инде, яз! Актарылып кил син,
Тугарылып кил син, көттермә!
Вакытында яз кичермәгән яз —
Бу бит тормыш түгел, бу — төрмә!

Бәлки, безгә дигән яз ят ярны
Чәчәкләргә инде чигәдер?
Иртәлисем килә бу язларны,
Иркәлисем килә нигәдер...

*1996*

## Шагыйрь коесы

Энә белән кое казыды ул,
Аркан сузып төште төбенә.
Төшмәс иде, тамган яше өстән
Көмеш чишмә булып күренә...

Юк, чишмә юк!
Типми иде чишмә!
Катламда моң әлегә тын тора.
Шагыйрь исә күзләрен йомган да
Чишмәгә дан җырлап утыра...

*1981*

## Иген сабагы

Игеннәр агарып килә...
Сабак хәвефле уйда:
Урылмый, башаклы килеш
Каласы килә буйда.

Бөртеген капкорсак итеп
Туендырасы килә,
Таңның сары угызында
Коендырасы килә.

Чайкалып йоклый басулар,
Башаклар йөгерәләр.
Бөртекләр дә, сабыйлардай,
Йокыда өлгерәләр.

Сабак-ана башагына
Бишек җырлары җырлый.
«Мин дә йоклыйм!» — дигән булып

Ясалма итеп гырлый...

Бөртек хакына — ураза,
Аягөсте ач тора:
Намаздан төшми, тамырга
Көн-төн авыз ачтыра...

Дерт итә урак-теш, йомран
Тишектән сызгырса да;
Ураклы кош-корт очышта
Ярышлар уздырса да;

Дерт итә ураклы, кояш
Кызганмый кыздырса да;
Ураклы яшен сыздырып,
Җил-давыл туздырса да...
...Белалмый сабак: тере җан
Яшәеш чиратында
Урактан урылмый калмый
Мәхәббәт сиратында.

Чөйми-черетми, басуга
Урак кергәнгә күрә,
Сабак үзе бөртек аша
Үлемсезлеккә керә.

Ул күрми, галәм күрә.

*1996*

## Күләгәсез урман

Ат күзләре белән түшәлгән юл —
Без тормышка синнән башландык.
Ат яшьләре юган бу юл бүген
Ташсыз кабер сыман ташландык.

Аһ, Кралов!*
Балачак урманым!
Синнән өзеп алган балтырган,
Минем моңны акташ чарда чарлап,
Зәңгәр чарлакларга** чаптырган!..

Аһ, Кралов!
Кара урман! Көндез
Печән чабып, төндә ат чабып,
Палищщик***тан урлап, синнән генә
Шарт аудара идек матчалык.

Менә бүген куйныңда ауныйм дип
Кайткан идем — сине танымыйм!
Урманнардан шәрә колга калган,
Ниләр генә булды, җаныем?!

Яфракларың кая? Сайрар кошың?
Синме безнең җиләк киләте?
Корыган,
корыган имән
кочып җылыйм —
Урманнарда имән үләте!..

Агачларны колониаль сөю
Шундый дәһшәт белән, тәүбәсез

Көйдергән ки —
Мәңге тере урман
Үлгән — күләгәсез, шәүләсез!

Буш кәүсәләр бозык кавем сыман
«Туй чапмыйлар, бала тапмыйлар».
Очкычлардан агу сибеп, урман
Шәүләсенә кадәр саттылар!..

Исәр кәүсәләрдән исәрләнеп,
Саташам, аһ, үземә кул салам! —
Кайтар, урыс, кара урманымның
Кара шәүләләрен булса да!..

Ходайга ялварган әсирләрдәй,
Буш ботактан күкне шакарып,
Ат күзедәй шартлап чыгып урман
Ава —
Куя галәм чайкалып.

...Чираттагы имән гөрселдәгәч,
Киселде иң актык өметләр.
Бер пычкысыз урманнар аудара
Тамыр кырмыскасы — термитлар...

*1997*

*** * ***

*Фәүзия Бәйрәмовага*

Урам аша — ике эмигрант,
Туган җирдә, Татарстанда,
Буран аша —
Гүя чит илләрдән
Хәлең беләм коштан, дустан да...

Кызыл чүпрәкле бау — безнең чик бу.
Аучы халкы, тотып колгалар,
Һәр куакның эчен савып, имеш,
Безне түгел — бүре сугалар...

Урамнарга ялгыз чыкма, дисең.
Үзең белән ал бер сак, дисең.
Саксыз йөрим: беләм, доган белән
Барыбызны, сеңлем, саклыйсың.

Бер камышның ике буыныдай,
Бер туй, бер буй, бер үк уйдан без —
Җиргә сәләт булып туган өчен
Алдан һәлак булып куйган без...

Аягүрә килеш чери кеше.
Кояшы да әллә нишләде:
Синнән ялкын алып янды, янды —
Кеше арасына төшмәде...

Синең тәрәзәңә карап яшим —
Анда ләйсән ява яшенләп.
Яшен күзен ачтым, шунда мәллә
Безнең татар серен яшергән?

Яшен күзе күзәтү астында
Яше белән тозлы кан ялый.
Үзәгендә яшь кенә Абыстай
Энҗе энә белән җан ямый...

...Урам аша — ике эмигрант,
Туган җирдә, Татарстанда,
Буран аша —
Гүя чит илләрдән
Хәлең беләм коштан, дустан да...

*1997*

## Сабантуй Сарыгы

Эссе. Бөркү. Сабантуй кояшы
Котырыпмы бүген котыра:
Жирный райбашаклар уртасында
Арык
Илбашы да эреп утыра.

Бер як читтә җиңүчегә махсус
Симертелгән сарык тәкәсе, —
Бораумөгез, гүя бу тамаша
Мәгънәсенең алтын тәңкәсе! —
Иртәдән үк казыкка бәйләнеп,
Көеп мәхрүм су вә азыктан,
Ычкынырга уйлап та карамый
Үзен әсир тоткан казыктан,
Күзе тонып, урынында оеп,
Кымшангалаштыра, таптана,
Май ярысы бөргән бәбәгеннән
Эреп, җиргә тып-тып май тама...

Кайчан бетәр: гарык булды Сарык.
Халык арды бушны кичереп.
Хөкемдарлар нәрсә? —
Көрәшчеләр
Бу мәйданга чыга исереп.
Һәм менә — ниһаять! — ачыкланды
Алколоид очкан «мунчада»:
«Арча җиңгән! — Ур-ра-а-а! — Кукмарага
Астан аяк чалып булса да...»

Кинәт Сарык күккә ашты. Кемдер
Йолдызлыкны гүя актарды.
Гүя бүре, теш белән шакарып,
Җилкәсенә аны аткарды.
Йолдызлыкта күзен йомды Сарык.
Җир кул чапты — «һәйкәл салдылар».
Пычак — ялт-йолт — гүя җиңүченең
Җилкәсенә менгәч чалдылар...

## * * *

...Дистә еллар үткәч, тарих кушып,
Бу Галәмгә күчкән Сарыкның
Күзен ачып карап булган булса,
Карашында
Мескен халыкның —
Райбашакларының кочагыннан
Ничек ат кочарга өйрәтеп,

Атсыз калган Илбашыбызның да
Калкыр иде сәер сурәте...

*1999*

## Балачак хатирәсе

Тымызык яшел яңгырның
Терекөмеш тамчылары
Сикерешеп бии туфракта,
Кисә ут камчылары.
Без исә лапас астында,
Паласта, чыланмыйча,
Такмак әйтәбез*, суганны
Авыздан чыгармыйча:
— Әпи-па-па, пи-па-па,
Маһи әби йон ката!..

Их, сөттәй җылы яңгырның
Яшькелт матурлыклары!
Балачак уеннарының
Кечкенә зурлыклары!
Риф, Камиле, Зыясы,
Вәкиле, Минзыясы,
Хәмдия, Гадәниясе,
Рәмзия, Хәниясе:
— Әпи-па-па, пи-па-па,
Маһи әби йон ката!..
Кайдадыр көйри калалар,
Авыллар көлдә бары, —
Без исә үткән сугышның
Атасыз балалары, —
Лапаста, яңгыр астында,
Паласта, суган кабып,
Әйтәбез такмак, очсызлы
Такмакта хикмәт табып:
— Әпи-па-па, пи-па-па,
Маһи әби йон ката!..

*1982–1999*

## Сәйдәш*

*(Җыр)*

Сандугачлар сайрый тугайда:
Сәйдәш, син кайда? Сәйдәш, син кайда?

Тынып кала елга агышы,
Ишетелә Сәйдәш тавышы:
Әле сезне уйлап, җыям илләр буйлап
Татар моңын, татар сагышын.

Тургайлар өзлегә басуда:
Кайда ул моң, Сәйдәш, моң кайда?

Җилләр тынсыз кала үрләрдә,
Сәйдәш җырлый туган түрләрдә:
Татар моңы дигән үлемсез моң
Чишмәләрдә, туган җирләрдә,
Туган илдә, туган телләрдә...

*2000*

## Кәркәледә, көзнең соңгы көннәрендә

Көн караңгы. Ут аласы килә.
Яктылыкны гүя чат токан:
Дөм караңгы булган булыр иде,
Ярый, җирдән кырпак яктырткан.

Кем бакчада чүп, сабак яндыра,
Басулардан килә гөрелте.
Трактор артыннан ак кырпактан
Көмешләнеп калган сөренте.

Кәркәлегә каз өмәсе килә!
Симез казлар тыгыз җил сибеп, —
Таудан очып төшеп гөрселдиләр,
Бүксәләре белән җир сөреп...

Тыелалмый йөгреп баралар да,
«Гаң-гаң»галап, һава соскылап,
Җыелыша, кырпакта тәпиләрдән
Челтәр дә генә челтәр эз кала...

Карт өянке оеп бу казларның
Каңгылдашып кайткан моңына,
Кырпак көмешен коя
Тәүге суык
Туңдырган сукмакка тын гына...

...Карт өянке ул — мин. «Сине сөям»
Дигән хәбәреңне алгач та,
Сине көтә-көтә әйләнгәнмен
Өянке дигән моңсу агачка...

*2001*

## Ялвару

И бөек татар әдәбе,
Гасырлар исән җилеп,
Кол Галиләрдән башланып,
Туктадың миңа килеп.

Шашкан караштан ут чәчеп,
Төшеп ташкын хисләргә,
Аласың миннән сораулар:
Йә әйт, безгә нишләргә?

И бөек татар әдәбе,
Имгәнми бер яуда да,
Кушучлап йолдызлар атам
Иң соңгы олаулардан.

И бөек татар әдәбе,
Теләсәң, мине күмер
Ит тә бир син милләтемә
Үлемсез дигән гомер.

*2004*

## Авылдан чыкканда

*Остазым профессор Иван Григорьевич Пехтелев истәлегенә*

Ай астында атсыз үстем. Шуңа
Ат кадерен яшьли аңладым.
Ат күзенә сызылып кергән үргә
Утырып кына менә алмадым.

Бөреләр дә әнә яфрак ярып,
Күккә яшел терәү териләр.
Безнең күздән чәчрәп чыккан яшьләр
Йолдыз булып очып йөриләр.

Ат күзедәй саф яшь белән тулган
Чокрын чыккан чакта авылның,
Аттан төшеп, йөктән артта, үрдә
Үз йолдызларыма абындым...

Бу йолдызлар, ат куган җайдактай,
Бер-берсен камчылап куалар.
Ай да керле икән!
Җиң сызганып,
Камзулын салдырып юалар!..

Йолдыз юган алтын камзулларда
Галәм иңләгән Ай — вәхи бу!..
Туган ягым, аһым, — бер тузаның! —
Күрешмәсәк, йә, хуш, бәхил бул!..

Аһ, Кәркәлем! Синең һәр йолдызың
Якты сагыш белән каюлы.
«Кайтырмы?» дип кара буразнада
Солдат аелыдай Ай елый...
Болар монда минсез ничек яшәр?
Зәгыйфь булмасмы уй-буйлары?
Инде тагын... — инде ничәнче кат! —
Минсез үтәр сабан туйлары...

Без киткәндә биксез булган йортлар
Инде ярты гасыр биклеләр.
Таш астыннан ачкыч табып, безне
Ачар затлар
Туганнармы? Туса — нишлиләр?

Әлифне тик үлемсез хәрәкә
Аваз итсә айдай сапланып,
Мин кайтырмын
Җәяү чыккан йортка,
Гарәп акбүзенә атланып...

*2000–2004*

## Бәләбәй калкулыгында

*Шагыйрь Әдхәт Синугыл истәлегенә*

Миллионнар хакына
Милләт диеп янды.
Кабрендә ташсыз да —
Берьялгызы калды.

Ул Тукай нәселеннән,

Ятим шагыйрь иде.
Залимне чаяндай
Чажлап чагар иде...

Инде Куганакта,
Борынгы зиратта
Ята минем дустым —
Бармый анда хат та.

Моннан ерак түгел
Минем Кәркәлем дә.
Яшәп яткан булам,
Теремен әлегә.

Мин дә, бәлки, шунда,
Бәләбәй калкуында,
Җирләнермен, димен,
Өязем алкымында.

Әгәр шул бәхетне
Итсә Ходай насыйп,
Ятарбыз без икәү
Шигырьләр алмашып...
Ике ятим шагыйрь,
Ике яхшы кеше.
Бу җир җиләкләре,
Ике алма төше.

Ыңгырашырлар сулар,
Ыңгырашыр бу җир.
Чыгармы дип бездән
Тагын бер чын шагыйрь.

*2004*

## Беренче кар алдыннан

Лычкылдап ята басулар,
Оеп утыра урман.
Талкынган ак сүстәй үтә
Томан артыннан томан.

Агачлар шәрә. Яфраклар,
Өзелеп төшеп кыллардан,
Үлгәннәр бергә түшәлеп —
Акларда, кызылларда.

Чишмәләр акрын агалар —
Көмештән куерганнар.
Гүя карларга үзләрен
Капларга боерганнар.

Менә-менә кар төшәрдәй,
Төшмәсә, менә хәзер,
Яфракларны кардан каплап
Ятарга үзем әзер.

*2005*

## Көз

Көн сүрән. Кар, кара яңгыр,
Һавалар асылынган.
Сыерлар гөпелдәп кайта
Чөгендер басуыннан.

Яшел уҗымнар өстендә
Кар уйдыклары ята.
Туймас тамак сөтбикәләр
Уҗымга тагын тарта...

Сары май йомарлагыдай
Салам эскертләре дә
Рәт-рәт булып йөзеп йөри
Кара җир өсләрендә.

Тынычлап калган басулар
Келәткә кергәч уңыш,
Киерелеп, кышкы йокыга
Күңелне били тыныч.

Авыллар торып калганнар
Сөргән җир эчләрендә.
Каңгылдап казлар кычкыра
Ямансу кичләрендә.

Әлегә кара һаваны
Тор-рыйклап, әнә, кара,
Тырный-тырный, торналарның
Ыргагы очып бара...

...Соргылт төс ничек басса да,
Изсә дә баткак вә ләм,
Барыбер якты бу дөнья,
Барыбер нурлы галәм.

*2001*

## Мадьяр көйләренә

*Зөлфия кызыма беренче баласы — оныгым*
*Айдар туувы уңаеннан*

Чәең суынмасын, бала,
Яңартып тор аны, кара.

Пышшималки, пышшимала*,
Чәең суынмасын, бала.

Син тауларга кара, бала,
Тау да үзенә юл сала.

Пышшималки, пышшимала,
Син тауларга кара, бала.

Җирдә иң бөек сурәтче
Кем ул? Белсәң, бала, әйтче!

Ана! Димәк, син ул, бала,
Балаңнан галәм нур ала!

Пышшималки, пышшимала,
Балаңнан галәм нур ала!..

*2000*

## Әнкәм каберендә*

*(Романс)*

И газиз әнкәм, ул синең гәлсәрдәй күз яшьләрең
Нур чәчә күкләрдән, гүя ак йолдыз тәлгәшләре.

Хәтта фаҗигаи яшең нур сипкәч төнгә карап,
Биргәнсең мине дөньяга энә күзендә сайлап.

Кайчак бу моңсыз тормышта мин өшим, бозга калам;
Ятсам кабреңә, и анам, кузыңда кайныйм, янам!

Тыңлыйм кабреңне... Ишетәм: бүген һәм киләчәктә
Җир йөрәге синдә тибә һәм мәңге тибәчәк тә.

*2001*

## Алла бәндәсе

*Авылдашым мөгаллим*
*Азат Хәмидуллинга*

Юл буе көнбагышыдай, —
Чәчкәсе тузан гына! —
Кул күтәреп юлдаш көтәм,
Ә гомер —
Узган гына...

Әйттеләр сине килә дип.
Мин әйттем: Азат килеш,
Ул килми калмас, азат зат,
Азат килергә тиеш!..

Киләсең, Алла бәндәсе!
Өязе ташлыкларында
Башаклар ыңгыраштылар
Тулгак тансыкларында.

Туды бөртекләр елашып,
Эре, ак, чиста, шатлар,
Гүя юынып, елгадан
Йолдызга шигъри атлар
Сикерде, гүя нур чәчеп,
Чакматаш күзләренә
Тулдылар шыплап йолдызлар
Өязе үзәненә.

Хәлсез ауган буш башаклар
Чак кына кыбырдыйлар.
Йөкләрдә, бүрәнәләрдәй,
Йолдызлар шыгырдыйлар.
Мин әйттем: әгәр бу килү
Булса да чиксез газап,
Азат барыбер килер ул,
Юлына маяк кадап.

Мин үзем үлеп канәгать
Эшләгән эшем белән.
Киләмен Өязем буйлап
Яраткан кешем белән.

Бер бүләк тә кирәк түгел,

Мин үзем сезгә бүләк.
Ходайдан килгән бүләкне
Бетерерменме түләп?

*2001*

## Иске Кармәттә Хәсән Туфан музеенда

«Президиуму Верховного Совета СССР.
Я обвиняюсь в основном в сочувствии к японским самураям...

Прошу Вас, как одного из лучших сыновей великого народа, направить меня на самый кровопролитный участок войны, дать мне поручение, требующее неминуемой смерти, одевшись в гранаты, броситься под военную машину самураев, направиться в торпеде рулевым в сердце вражеского корабля и взорваться или дать подобное целесообразное поручение, чтобы спасти жизнь многих.

*11 августа 1945 года. Хасан Туфан, поэт*».

*Дивардагы язудан*

Мин һәйбәт улың түгелме,
Кодрәтле империям?!
Төрмәңнән тәхтең алдында
Чал башкаемны иям.

Мин һәйбәт улың түгелме,
И шанлы империям?!
Төрмәңнән тугрыдан тугры
Колыңны күрче, диям.

Миңа ат калдырмасаң да,
Атың буласым килә.
Миңа хат яздырмасаң да,
Хатың буласым килә.

Сиңа булган мәхәббәтем
Җан читлегемдә көйри.
Синең өчен әзер үземә
Ясарга харакири.

Арык гәүдәмне ук итеп
Кордырт та син пушкага,
Аттыр мине көнчыгышка —
Самурай-япошкага.

Ясат миннән самурайны
Издерә торган бәләк.
Илдәшләр гомерен саклап,
Мин генә булыйм һәлак.

Бәйләп гәүдәмә тоташтан
Гранат бәйләм-бәйләм,
Шартлатыйм самурайларның
Иң куе җирен сайлап.

Торпеда рулевоенда —
Мина булып мин аңа —
Шартлатып дошман корабын
Күрсәтимче дөньяга!..

...Музеен күргән сәгатьтә
Диссидент остазымның
Күз яшемдә буылып укыйм
Диварда хат язуын.
Туфанча нечкә киная,
Туфанча яшерен сабыр.
Бу хатка утыз елдан соң
Орденлы* булган шагыйрь.

Бу хат күзгә күренмиме?
Түгелме берәр ялгыш?
Ялгыш түгел. Хак. Татар — хак.
Хак безнең шундый язмыш.

*2002*

## Татарстан

Гомер буе әйталмыйча йөргән
Әйтер сүзем әйтәм, дусларым:
Җирдә,
күктә,
суда,
утта
һәм дә
Кояшта бар Татарстаным!

Яула, даула, шаула син, дип түгел,
Аңла син, дип әйтәм, дошманым:
Син күтәргән кашыктагы аштан
Күтәрелә Татарстаным.

Көтеп-көтеп көтек булганнан соң,
Бик ваклана биреп китмәгез.
Биш гасыр бил бөгеп бетмәгәндә —
Бүген, бил турайткач, бетмәбез!..

Куштан түгел, сирәк язмыш кушкан
Каһарман җыр, гайрәт дастаным —
Иген арасыннан шат елмайган
Нәфисәм син,
Татарстаным!

*2004*

## Мәккәгә якынлашкан кичтә

Мәккәгә җитеп киләбез,
Мин бүген йоклый алмам.
Бердәнбер итеп яраттың,
Бердәнбер Раббым-Аллам.

Үркәчле таулар тезмәсе,
Дөя кәрваннарыдай,
Мәккәдән зәмзәм суларын
Ташый күз алларымда.

Көчәя бер тойгы миндә,
Көчәя дөньякүләм.
Мин Мәккәдә туып-үсеп,
Өемә кайтып киләм.

*2005*

## Пәйгамбәребез каберендә

Басып торсам да тик бүген
Синең нурлы кабреңдә,
Яшисең син кабрең берлә
Мәңге минем бәгъремдә.

Кабреңнән чыккан нур илә

Кальбемдә рух яңартам.
Яңартам да, яңгыратып,
Өммәтемә таратам.

*2005*

## Нишләп?

Мин энҗе чүпләүче булдым,
Инде үләргә әзер.
Инде әзер, үләм хәзер,
Алмыйча бер тиен әҗер.

Ничекләр шулай була ул,
Тел тешләп, эшләп-эшләп,
Көн вә төнен энҗе чүпләп,
Ач булдым икән нишләп?

Менә әле әрәмәлектә
Юа җыйдым да күпләп,
Туйдырам тамак, җыр сузам,
Моңны сүз белән җөпләп:

«Һе-һе-һей!
Кайчакта патшалар миннән
Энҗе җыйдырса көчләп,
Патша да юк, ил таркалды,
Мин исән икән нишләп?
Һе-һе-һей!
Кая булдылар икән, дим,
Минем җыйган энҗеләр?
Энҗе миндә дип, ач килеш
Ашый мине көнчеләр,
Һе-һе-һей!»

*2006*

## Наилә апага хатлар

### Беренче хат

Наилә апа!
Мин авылда әле.
Төне булды бүген караңгы.
Көтмәгәндә сезнең йорт нигезен
Шахтер сыман «чокып» карадым...

Болай, димәк:
Күзгә төртсәләр дә
Күренмәс бу көрән-карада
Лачтыр-лочтыр көзге пычрак ерып
Килгән чакта, кайсы арада
Мин адаштым? Сулга атлыйм — чокыр,
Уңга атлыйм — кемнең коймасы?
Җитмәсә, җил!.. Туры китәр идең,
Алда уты да юк, ичмасам!..

Күзем йомам... Тукта, кемнәр елый?
Нинди нигез, ниткән терәкләр
Ыңгыраша, тәрәз капкачыдай,
Җилдә үкси, калып үләттән,
Иңри йорт-җир, койма-келәтләр.
Сез булып... Сызланып һавада
Лепер-лепер, аннан чаштыр-чоштыр,

Шыбыр-шыбыр, аннан дөбер-дөбер
Килеп, буталышып яңадан,
«Коткар!» диеп шаулый тирәкләр!
Аһ, тирәкләр — ярсу йөрәкләр!..

Маңгай ярып, чабам шул тарафка.
Аһ, тирәкләр, сез бик кирәкләр!
Сугылып туктыйм. Капшыйм. Тирәк. Кочам.
Аһ, тирәкләр, сез бик зирәкләр!..
Йөрәгемне куеп, ихлас белән
Үзәккәен тыңлыйм кәүсәнең:
Азат әсирләре җырлый иде
Сәвит иле дигән кәнсәнең!..

Көмеш аһәңеңне аерып алып,
Кәүсәдәге барлык аһәңнән,
Тальян уйнап, мин шахтадан мендем,
Җир йөзендә иде җәһәннәм!..

Бер буынсыз калып караңгыда,
Кулы да бәйләнгән әсирдәй,
Гүя тирәк түгел, терәк эзләп,
Тәмам хәлдән таеп, бәлҗерәп,
Егылып китмим диеп колач җәйгәч,
Аңламадым, нигә каушадым?
«Исәннәрме?!» диеп кулым сузып,
Кәүсәдән кәүсәне капшадым...
Менә Рәшит абый... Тирәкне һәр
Туганына атап утырткан.
Уналтыда, үз йортыннан качып,
Ватан сугышына юл тоткан...

Ә монысы Әптерәй тирәге.
Җырчы, эшчән иде шулчаклы.
Кызык өчен генә мактаныр да,
Юри эре ярыр борчакны...

Бу тирәк — син, Наилә апа... Әгәр
Син җыр сузсаң, синең тавыштан
Салават күпере күтәрелә иде
«Кыргыз юлы»ндагы арыштан...

Монысы — Сәбилә... Бу — Заһирә инде...
Түзем бетеп качты Ташкингә.
Ә бу — Наил... Кәнүшнәйдә яшәп,
Баш үсүдән үлде, мескенкәй...

Алты тирәк — бер рәт исән тирәк!..
Колачка чак сыяр тирәкләр.
Һәр кәүсәне аерым кочып чыккач,
Көч кергәндәй булды беләккә...

Суык җилдә, көзге кара бозда,
Яланаяк, авыл очыннан
Килеп өшегәннәрдер...
Ничек җылытыйм?
Ни ашатыйм кайнар учымнан?

Көтмәгәндә балачакка кайтып,
Зиһенемнән, ахры, ычкындым,
Караңгыда, шашып: «Сез өйгә ник
Һаман кермисез?!» — дип кычкырдым...

Тирәк — сирәк, зирәк, бик тә кирәк
Кардәшләрем мине аңлады.
Яфраклары белән күк куптарып,
Бертавыштан җилдә шаулады:

— Әтиебез безнең урман саклый,
Безне саклый алмый, карагыз:
«Күзгә күренмәгез!» — диеп, безне
Тышка куды үги анабыз.
Өшегәндә без кочаклашабыз,
Гүя таркатылмас көлтәбез.
Яшел чирәм чыккач, җылы җиргә
Басар өчен язны көтәбез...

...Йөрәгемне куеп, ихлас белән
Үзәккәен тыңлыйм кәүсәнең:
Туганнарым җырлый кар базында
Совет иле дигән кәнсәнең!..
Наилә апа!
Авылдагы көннәр
Бик тиз үтteләр дә киттеләр.
Бу тирәкләр җанны өттеләр дә,
Тагын бер кат шагыйрь иттеләр...

*1979*

**Икенче хат**

Наилә апа!
Сиңа менә тагын
Хат язмакчы булдым авылдан.
Сездә, Мамадышта, хәлләр ничек?
Бездә халык ару савылган.

Авыл — сәрхуш. Кичә җырлап эчеп,
Манарасын кискән алкашлар,
Бүген җырламыйча, яшрен эчеп,
Ишан-хаҗи булып маташа...

Рәсәй! Үги ана! Татарыма
Рәхмәт әле исән калуга.
Урыс корабында айнып булмый,
Косык белән тулган палуба.

Галләм ялга кайткан. Балалары
Кәбестә суыдай тоныклар.
Марҗасы кайтмаган. Нурмый картка
Тик урысча мөгри оныклар.

Нишлим? Үкенечле яшьтән тыгылып,
Өерелтеп кочтым аларны.
«Катнаш» мәхәббәтнең мәхәббәтсез
Булуын татар берчак аңлармы?
Аңлармы?! Аңлармы?! Аңлармы?!

Аңламаса — хана!
Бу кол татар,
Котылып урыс таккан холыктан,
Үзен генә түгел, урысны да
Коткарырга тиеш коллыктан!..

Наилә апа!
Монда, җаный, буран.
Көрт яу булып таудан сикергән.
Өянкеләр билдән кар эчендә,
Он тузгытып тарта тегермән.

Хәлим җизни быел да карларны
Фанер көрәк белән көриме?
Мәскәуский Татарстан һаман
Сиртмәле үкчәдә бииме?

Син һаман да, суы тәмле диеп
(Әйтмәсеннәр «Чәе пешмәгән!»),
Көянтәңне элеп төшәсеңме
Нократ буендагы чишмәгә?

Сиңа тагын нәрсә языйм икән?
Бер хәбәр бар — алма авырга.
Башкайларны ташка орып булмый,
Сабыр булыйк, булыйк сабырлар...

Урыныгызга колхоз йорт бетергән,
Өр-яңа хуҗалар күчкәннәр.
Беренче эш итеп, сезнең теге...
Теге тирәкләрне кискәннәр!..
Якты көндә бер буынсыз калып,
Күзләре бәйләнгән әсирдәй,
Гүя тирәк түгел, йөрәк эзләп,
Тәмам хәлдән таеп, бәлҗерәп,
Тирән көртне ерып эчкә үттем,
Җанда моң мәхшәре кичереп,
Кар иснәдем бөре исләреннән,
Кар да гүя иде исерек.
Егылып китмим диеп колач җәйгәч,
Ник какшадым, нидән каушадым?
«Исәннәрме?» диеп, көрт эчендә
Төпсәдән төпсәне капшадым...

Туңган бармакларда бушлык җырлый,
Юк, эләкми иде төпсәләр,
Төпсәләрне төпләгәннәр икән,
Калдырмыйча хәтта җепсәләр...

Наилә апа!
Синең аһәңеңне
Аерып алып барлык аһәңнән,
Хәтер эзләп, мин шахтадан мендем,
Кулда — тальян, җирдә — җәһәннәм!..

Мин яңадан балачакка кайтып,
Зиһенемнән, ахры, ычкындым, —
Тешемдә кар чәйнәп: «Сез өйгә ник
Һаман кермисез?» — дип кычкырдым...

Тирәк — сирәк, зирәк, бик тә кирәк
Туганнарым мине аңлады,
Бертавыштан ак карларда кайнап,
Галәмне куптарып шаулады:

«Гомер буе тышта сүс талкыдык,
Сүстән әвереләдек талкышка.
Талкышыбыз күктә балкыш булды,

Үзебез әйләндек аккошка...»

Наилә апа!
Яңа йортка күчкән
Егет яхшы — Фәиз малае.
— Абый, — ди ул, күзен челт-челт йомып, —
Язлар җитсен, җитсен май ае,
Очтан очка тирәкләр утыртам,
Бу бакчаны сөрәм-кистерәм
Яңабаштан... Габдрахман* картка
Атап монда гөлләр үстерәм...

Шулай булсын иде! Тизрәк кенә
Җитә күрсен иде май ае.
Бу нигездә матур гаилә корып,
Яши күрсен Фәиз малае...

Наилә апа!
Тагын шунысы кызык:
Китапсыз хезмәттә алҗыган
Фәиз малаеның күзләрендә
Күрмәдем мин һичбер фаҗига...

Аның өчен бу барыбер иде.
Рәшит тирәкләре — нәрсә ул?
Имеш, искеләрдән арына да,
Өр-яңасын үзе чәчә ул...

Ул башлаган яңарышта иман
Булган булса, бәлки, күпердә
Арбасыннан төшеп калмас иде
Хәтер,
Буш мичкәдәй дөбердәп...

Наилә апа!
Бездә, җаный, буран.
Көрт яу булып таудан сикергән.
Өянкеләр билдән кар эчендә,
Он тузгытып тарта тегермән...

*1991*

**Өченче хат**

Наилә апа!
Ник яратам сине,
Охшаганга мәллә әнигә?
Нигә әле Кырым ярыннан да
Хат язмаска сиңа? Ә нигә?
Җитмәсә, охшагач әнигә?!

Исеңдәме, кичен казлар таудан
Башак урып, басу сыеклап,
Сары айны томшык кашыгына
Төяп төшә иде кыеклап?

Исеңдәме, Өязе сулары
Чуерташта чәчрәп, чәчелеп,
Ихахайлап ага иде, синең
Бөҗраланып аккан чәч кебек?

Үпкәләмә миңа, без сау чакта
Сирәк килә диеп бу нигә?

Нишлим, утырып янам!
Бар татарга
Бирәү генә бит мин әлегә!..

Ут йотасың тап булмасын диеп,
Пычагына берәр гыйлләтнең.
Ни булса да әзер: егылырмын
Кайнар кочагына милләтнең...

Мин итекле идем... Чабатада
Сөзеп көзнең яңгыр тутыгын,
Әрним: милләтемнең йөрәгеннән
Ямап өлгералмыйм ертыгын...

Нәселемнән беркемне танымыйм,
Кемне күрсәм, калам гаҗәпкә:
Харап булдык бар малны юк итеп,
Хәерчегә кердек әҗәткә...

Исеңдәме, бермәл таптык диеп
Мендәрле Кулында шәп уйдык,
Җиләк түгел, агулы гөмбәгә —
Чит кавемгә таеп егылдык?

Наилә апа! Ник яратам сине,
Охшагангамы син әнигә?
Син әйт,
Нигә көмеш солыларның
Күләгәсе юеш? Әйт, нигә?
Охшагангамы син әнигә?

*1996*

## Эчтәлек

Яна-яна иҗат итә. *Р.Фәйзуллин* ..........................

**«Яшьлегем хатирәсе» гөлләмәсеннән**

Кереш сүз ..........................................
Туган җиремә ........................................
Туганнар каберлегендә .................................
Җылы икмәк-җирем . ................................
Кояш көнчыгыштан китек чыкмас... ........................
Тальян моңы .......................................
Кил бире, күз алмам! .................................
Язгы яңгыр .........................................
Иркәлә, бәгърем... ....................................
Әманәт ............................................
Колмак җыя кызлар ...................................
«Тарих кирәк кешесен...» ...............................
Гади күренеш ........................................
Бу күзләрне кайда күрдем соң мин? .........................
Үзем турында .......................................
Сезгә ..............................................
Баймак ............................................
Тубин җыры ........................................
Курай .............................................
Атлар көткәндә ......................................
Иртән талга көмеш урала... ..............................
Тыйнаклык .........................................
Авыл картлары ......................................
Сибай .............................................
Ян! . . .............................................
Җитлегү ...........................................
Өстә минем йөрәк кылын... ..............................
Кайтучы нотыгы .....................................
Кышкы фантазия .....................................
Динис Исламов истәлегенә ...............................
Килеп чыгар идең... ...................................
Күз сирпесә... .......................................

«Мендәрле Кул» чишмәсенә мөрәҗәгать .....................
Финдлей ...........................................
«Арыш ерып кайткан чакта...» ............................
Тәрәз төбендә төн буе... .................................
«Күкләргә карыймын...» ................................
Каз йолкыйлар кызлар ..................................
«Адаштыра торган төн иде ул...» ...........................
Чыны-шаяруы бергә....................................

**«Сезне юксынам» гөлләмәсеннән**

Илсөяр кызым белән сөйләшү .............................
Кайсыгызны юатыйм? ..................................
Мәхәббәтем турында монолог .............................
«Әле яктырып бетмәгән...» ...............................
Кавказ .............................................
Өзелгән кыл ........................................
Татырлы сулар .......................................
«Заман, минем белән ни кыласың?..» ........................
Биштау белән хушлашу .................................
Кафтау язы .........................................
Өязе .............................................
Миләш ............................................
Кичке җайдак .......................................
Кайту .............................................
Талант турында баллада ................................
Хәтерләү ...........................................
Алтын тәңкә жыры ....................................
«Йолдызларда сәгать ничә икән?..» .........................
Басуда .............................................
Шигырьгә үтенеч .....................................
Онытылган сүз турында баллада ...........................
Авылдашым Зәбир дустыма ..............................
Төнге авыл ..........................................

**«Яңарыш чорында» гөлләмәсеннән**

Татар китабы ........................................
Татарлар, берләшегез! ..................................
«Адаштым таныш урында...» .............................
«Вулкан төбендә, тетрәнеп...» .............................
«Казыймын кызгылт томаннар...» ..........................
Трибунадагы телсез ....................................
Энҗе турында баллада ..................................
Халык Бабасының теле .................................
Нурлылар жыры ....................................
«Түгәрәк Имән» төбендә .................................
Кеше эзләп киләм... ....................................
Ике елга тамагында ....................................
Ут ..............................................
Укучыма үзем турында .................................
Язгы нурлар ........................................
Без исән! ..........................................
Егъла, татар! ........................................
Балалар бакчасы .....................................
Хәсән Туфанга .......................................
Суфиян бабай бәете ....................................
Сагыш .............................................
Азнакайдан үтеп барышлый ..............................
Автобуста ..........................................
Кабанда давыл .......................................
Шагыйрь Кәрам Бакиров ................................
«Сине эзлим. Беләм, якындасың...» .........................
Заман башында ......................................
Бөреләр ............................................
Кырым. Таң ата. Беренче күрешү ..........................
Диңгез ярында кызына ..................................
Кырым ............................................
Айлы манара турында баллада ............................
Казан–Бакчасарай–Истанбул .............................
Дудай маршы ........................................
Телсез «Әтен» турында баллада ...........................
**«Төрле еллар — серле жырлар» гөлләмәсеннән**

Сыерчык карлары яуганда ...............................
«Буразнада идем. Өн ишеттем...» ..........................
Песи баласы ..........................................
«Очкын очты яшемнән...» ................................
Туган йорт тупсасында ..................................
Яңгыр килә ..........................................
Нормандия–Неман .....................................
Курортта очрашу ......................................
Язны көткәндә ........................................
Шагыйрь коесы .......................................
Иген сабагы .........................................
Күләгәсез урман ......................................
«Урам аша — ике эмигрант...» ............................
Сабантуй Сарыгы .....................................
«...Дистә еллар үткәч...».................................
Балачак хатирәсе ......................................
Сәйдәш ............................................
Кәркәледә, көзнең соңгы көннәрендә ........................
Ялвару ............................................
Авылдан чыкканда .....................................
Бәләбәй калкулыгында ..................................
Беренче кар алдыннан ..................................
Күз ..............................................
Мадьяр көйләренә .....................................
Әнкәм каберендә ......................................
Алла бәндәсе .........................................
Иске Кармәттә Хәсән Туфан музеенда .......................
Татарстан ...........................................
Мәккәгә якынлашкан кичтә ..............................
Пәйгамбәребез каберендә ................................
Нишләп? ...........................................
Наилә апага хатлар ....................................

Литературно-художественное издание

**Халим** Айдар
(**Халимов** Борис Назметдинович)

## Девушки на сборе хмеля

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Хәлим** Айдар
(**Хәлимов** Борис Нәҗметдин улы)

## Колмак җыя кызлар

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*. Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина.* Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*.Оригинал-макеттан басарга кул куелды 6.08.2008. Форматы 70×$108^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 9,10. Шартлы буяу-оттиск 9,45. Нәшер-хисап табагы 6,55. Тиражы 2000 экз. Заказ Т-891. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru. Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» полиграфия-
нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.